ХОККЕЙ



# Чемпион булу серләре

# Как стать чемпионом?

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010
Казань
Татарское книжное издательство

УДК 821.512.145-3-93:796
ББК 84(2Рос=Тат)-4:75.7
Ч36

Автор-төзүчесе *Гөлнара Сибгатова*
Автор-составитель *Гульнара Сибгатова*

Рецензенты *Алмаз Якупов, «Ак Бүре» БЯСМ тренеры*
Рецензент *Алмаз Якупов, тренер ДЮСШ «Ак Буре»*

Ч36 **Чемпион булу серләре** : хоккей = Как стать чемпионом? : хоккей / авт-төз. Г.Сибгатова. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 71 б. : рәс. б-н.

ISBN 978-5-298-01884-5

«Чемпион булу серләре: хоккей» китабы, иң кызыклы, иң мавыктыргыч спорт төрләренең берсе булган хоккейга багышлана. Китапта хоккей тарихы, уен кагыйдәләре, «Ак Барс» командасы, «Ак Бүре» балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбендә тәрбияләнүче хоккейчылар хакында сүз алып барыла.

Китап мәктәп яшендәге балаларга һәм спорт белән кызыксынучы киң даирә укучыларга адреслана.

Книга «Как стать чемпионом?: хоккей» посвящена одному из самых интересных и увлекательных видов спорта – хоккею. В книге можно найти информацию об истории хоккея, его правилах, о команде «Ак Барс», о хоккеистах – воспитанниках детско-юношеской спортивной школы «Ак Буре».

Книга адресована детям школьного возраста и широкому кругу читателей, интересующихся спортом.

УДК 821.512.145-3-93:796
ББК 84(2Рос=Тат)-4:75.7

ISBN 978-5-298-01884-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Сибгатова Г.Ф., төзү, 2010

## СҮЗ БАШЫ

– Морозов! – дип кычкыра Айрат, бар көче белән һөҗүмгә ташланып. – Пас бир миңа! Мин монда бит!

Капитанның җавабы үзен озак көттерми. Бер, ике – алка каршы як капкасына очып керә, һәм «Ак Барс» чираттагы җиңүен бәйрәм итә. Җанатарлар, сихерләнгәндәй, бары тик аның исемен кабатлый:

– Ай-рат! Ай-рат! Ай-рат!

Малай аякларын тоймый, ул бәхетеннән очып китәргә әзер... Кинәт боз ярыла, һәм ул каядыр төшеп китә...

– Айрат, улым, тор тизрәк! Мәктәпкә соңга каласың бит! – Кайдадыр якында гына әнисенең тавышы ишетелде.

Димәк, Морозовның пасы да, Айратның голы да, җанатарларның шатлануы да – барысы да төш кенә булган. Ә хәзер тагын мәктәпкә – гадәти көннәр дәвам итә...

Шулай да бу көн, дөресрәге, кич, бер дә гадәти булып чыкмады. Әтисе аңа бүген өр-яңа тимераяклар белән китап бүләк итте. Малай укырга яратмый иде. Менә хәзер дә, яңа тимераякларын киеп, урамга, дуслары янына ашыкты.

Айрат өенә кайтканда, телевизордан ниндидер интеллектуаль уен күрсәтәләр иде. Анда хоккейның килеп чыгышы турында сорау бирделәр, ахры, әтисе:

– Улым, ә син «хоккей» сүзенең нәрсәне аңлатканын беләсеңме? – дип сорады.

– Юк, әти...

– Эх син... Ә үзең хоккейчы булам дисең тагын. Яхшы спортчы спорт турында бөтен нәрсәне дә белеп торырга тиеш ул.

## ПРЕДИСЛОВИЕ

– Морозов! – закричал Айрат, всеми силами бросаясь в атаку. – Дай мне пас! Я же здесь!

Передача капитана не заставила себя долго ждать. Раз, два – шайба влетает в ворота соперника, и «Ак Барс» празднует очередную победу. Болельщики, как околдованные, повторяют лишь его имя:

– Ай-рат! Ай-рат! Ай-рат!

Мальчик не чувствует ног, он готов летать от счастья... Вдруг лёд трескается, и он куда-то падает...

– Айрат, сынок, вставай скорее! В школу же опоздаешь! – Где-то рядом послышался голос мамы.

Значит, это всё было лишь сном: и пас Морозова, и гол Айрата, и ликование публики... А теперь опять в школу – скучные будни продолжаются...

Но этот день, вернее вечер, оказался не таким уж обычным. Сегодня папа подарил ему новые хоккейные коньки и книгу. Мальчик не любил читать. Вот и сейчас, одев новые коньки, он поспешил на улицу, к друзьям.

Когда Айрат вернулся, по телевизору показывали какую-то интеллектуальную игру. Кажется, задали вопрос о происхождении хоккея, и тут папа спросил:

– Сынок, а ты знаешь, что означает слово «хоккей»?

– Нет, пап...

– Эх, ты... А ещё хочешь стать хоккеистом. Ведь хороший спортсмен должен знать о спорте всё.

– Но как же мне узнать? Я же не энциклопедия...

– Ә ничек белергә? Мин энциклопедия китабы түгел бит...

– Теләгең булса, чыганак табыла ул, – дип елмайды әтисе. – Бу юлда сиңа «Чемпион булу серләре: хоккей» китабы ярдәм итәр. Ул – «Спорт» сериясенең беренче китабы һәм хоккейга багышланган. Анда син әлеге спорт төренең тарихын һәм кагыйдәләрен дә, яраткан командаң «Ак Барс» турындагы мәгълүматны да, балалар хоккеена багышланган аерым бүлекне дә, бик күп фоторәсемнәрне дә табарсың. Менә, улым, рәхәтләнеп укы.

– Рәхмәт, әтием! Бу – иң шәп бүләк! – диде Айрат, куанып, һәм китапны шунда ук укый да башлады...

Кем белә, бәлки, берничә елдан малайның хыялы чынга ашар, җанатарлар нәкъ менә аның уңышларына сөенер... Ә бәлки синең уңышларыңадыр, укучым?

Бу китапны укып чыгуың белән син хыялыңның чынга ашуына бер адым ясаячаксың. Ул бары тик синең өчен – булачак **чемпион** өчен язылган бит!

– Было бы желание, а источник найдётся, – улыбнулся отец. – Тебе поможет вот эта книга – «Как стать чемпионом?: хоккей». Она первая из серии «Спорт» и посвящена хоккею. В ней ты найдёшь историю и правила этого вида спорта, и информацию о любимой команде «Ак Барс», и отдельную главу про детский хоккей, и множество фотографий. Вот, сынок, читай с удовольствием.

– Спасибо, пап! Это лучший подарок, – обрадовался Айрат и тут же начал читать книгу...

Кто знает, может, через несколько лет сбудется мечта мальчика и болельщики будут радоваться именно его успехам... А может, твоим, мой читатель?

Прочитав эту книгу, ты сделаешь один шаг к осуществлению своей мечты. Ведь она написана специально для тебя – будущего **чемпиона**!

## Хоккей сере

- «Хоккей» сүзе нәрсәне аңлата?
- Бу уен кайчан һәм кайда барлыкка килгән?
- Россия хоккееның тарихы

## Загадка хоккея

- Что означает слово «хоккей»?
- Когда и где появилась эта игра?
- История российского хоккея

## «Хоккей» сүзе нәрсәне аңлата?

*Хоккей сере әлеге уенның исемендә үк. «Хоккей» сүзе нәрсәне аңлата соң? Ул каян килеп чыккан?*

Бу хакта төрле фикерләр бар. Без исә аларның иң билгелеләренә – Британия һәм Канада версияләренә тукталырбыз.

*Британия* чыганаклары «хоккей» терминының килеп чыгышын «хау́ки» яки «хо́ки» сүзе белән бәйли. Урта гасырларда Англия графлыкларының күбесендә уңыш җыю бәйрәмнәре нәкъ шулай аталган. Әлеге бәйрәмнәрдә үткәрелгән уенның максаты тупны кәкре таяклар белән көндәшләр зонасына кертү булган. Шунысы кызык: бүгенге көндә дә АКШның көньяк штаты эшчеләре *хокки* – җир сөрү өчен җайлаштырылган чапкыга охшаш инструмент кулланалар.

*Канадалылар* исә бу мәсьәләгә карата башка ике төрле караштa торалар. Шуларның *беренчесе* буенча, «хоккей» сүзе мохауклар теленнән алынган. Кайчандыр алар чирәмдә шуңа охшаш уен уйнаганнар. Ул «хогий» дип аталган һәм «авырта» дигән мәгънәне белдергән. Баксаң, бу уенда җиңелгән як җәзалауга дучар булган икән. Канадада кабул ителгән версияләрнең *икенчесе* гадирәк һәм күпләргә таныш. Ул «хоккей» сүзенең килеп чыгышын «көтүченең кәкре башлы таягы» дигән мәгънәне аңлаткан борынгы француз сүзе «хокэ»га кайтарып калдыра.

## Что означает слово «хоккей»?

*Загадка хоккея уже в само́м названии этой игры. Что же означает слово «хоккей»? Откуда оно произошло?*

Существует множество мнений на этот счёт. Мы же остановимся на самых популярных: британской и канадской версиях.

*Британские* источники связывают происхождение термина «хоккей» со словом «хау́ки» или «хо́ки». Именно так в начале средневековья в ряде английских графств назывались праздники уборки урожая. Во время этих праздников проводилась игра с целью провести мяч изогнутыми палками в зону противника. Любопытно, что и сейчас в южных штатах США рабочие используют *хокки* – инструмент вроде тяпки, которым возделывают землю.

*Канадцы*, однако, придерживаются в этом вопросе двух абсолютно иных версий. По *первой* версии, слово «хоккей» взято из языка мохауков. Они некогда играли в похожую игру на траве. Она называлась «хогий», что означает «больно». Дело в том, что после игры побеждённые подвергались наказанию. *Вторая* из принятых в Канаде версий более проста и известна. Она относит происхождение слова «хоккей» к старофранцузскому «хокэ», что означает изогнутый пастуший посох.

## Бу уен кайчан һәм кайда барлыкка килгән?

Теге яки бу спорт төренең кайда барлыкка килүен төгәл генә билгеләү кыен, шулай да шайбалы хоккейның туган җире дип Канаданы, ә туплы хоккейның ватаны дип Россияне санау кабул ителгән.

## Когда и где появилась эта игра?

Трудно сказать, откуда пришёл тот или иной вид спорта, но родиной хоккея с шайбой принято считать Канаду, а хоккея с мячом – Россию.

Хоккейның Канадада килеп чыгуы турында бик күп карашлар бар. Шуларның берсе буенча, бу спорт төре башта Англиядә уйлап табылган, аннары инглиз укчылары аны Галифакска алып кайтканнар, һәм шәһәр халкы яңа уен белән мавыгып киткән.

1870 елларда ук шайбалы хоккей Канадада уздырылган кышкы спорт бәйрәмнәре программасына кертелә. Хоккейның беренче кагыйдәләре Монреаль университеты студентлары тарафыннан төзелә. Бозга куелган ике таш – капка ролен үти башлый, алар ярдәмендә шайба керергә тиеш булган аралык үлчәмнәре билгеләнә.

Существует много версий зарождения хоккея в Канаде. Одна из них гласит, что этот вид спорта сначала появился в Англии, а потом английские стрелки завезли его в Галифакс, жители которого увлеклись новой игрой.

Уже в 1870-е годы хоккей с шайбой включали в программу зимних спортивных праздников в Канаде. Первые хоккейные правила были сформулированы студентами университета в Монреале. Роль ворот стали выполнять два камня на льду, с помощью которых были определены размеры пространства, в которое можно забивать шайбу.

***Син беләсеңме?***

*Беренче официаль матч* 1875 елның 3 мартында Монреаль шәһәренең «Виктория» боз мәйданчыгында үтә.

***Знаешь ли ты?***

*Первый официальный матч* был проведён 3 марта 1875 года в Монреале на катке «Виктория».

Ул вакыттагы хоккей бүгенгесеннән бик нык аерылып тора. Һәрбер командада бары тик *тугыз уенчы* (хәзер *унсигездән* дә ким түгел) була, алар бер матч дәвамында алышынмыйча уйныйлар. *Шайба* (*алка*) түгәрәк агач кисәге рәвешендә була.

Футбол тарихындагы кебек, хоккейда да капкадагы *ятьмә* бик күп вакытлар узганнан соң гына кулланыла башлый. Беренче тапкыр ул 1900 елда гына барлыкка килә һәм балык тота торган ятьмәдән эшләнә. Шуннан соң шайбаның капкага керү-кермәвенә бәйле бәхәсләр (кайвакыт алар командаларның сугышуына да китергән) юкка чыга. Казыйларга һәм хоккейчыларга капка алынуын билгеләү шактый җиңеләя. Бераздан капкага *металл ятьмә* элә башлыйлар. Ул нык була, әмма кайвакыт шайбаның, бәреп кертүдән соң артка атылып китеп, капкачыны яки капка янында торган башка уенчыны җәрәхәтләү очраклары

Хоккей того времени очень сильно отличался от сегодняшнего. В каждой команде было всего *девять игроков* (сейчас не менее *восемнадцати*), которые играли весь матч без смены. *Шайба* же представляла собой деревяшку округлой формы.

Как и в истории футбола, *сетки* на воротах в хоккее долго не было. Впервые она появилась лишь в 1900 году и была сделана из рыболовной сети. После этого иногда доходившие до командных драк споры о забитой шайбе прекратились. Судьям и хоккеистам стало намного удобнее следить за взятием ворот. Затем на ворота стали вешать *металлическую сеть*. Она была прочна, но после удара шайба отлетала назад и иногда травмировала вратаря или игрока, находившегося у ворот. Этот недостаток смогли исправить второй *веревочной сетью*, натягиваемой внутри ворот для

күзәтелә. Әлеге кимчелекне бетерү өчен, бәрү көчен киметә торган һәм капка эченә тарттырылып куела торган икенче – *баудан ясалган ятьмә* куллана башлыйлар. Бүгенге көн сеткасы металл һәм баудан ясалган ятьмәләрнең кушылмасыннан гыйбарәт.

Шайбалы хоккейның беренче рәсми кагыйдәләр тупланмасы 1886 елда басылып чыга. Кагыйдәләр кодексының авторы Канада хоккеисты Райан Смит була. Шул ук 1886 елда Канада һәм Англия командалары арасында беренче халыкара очрашу уздырыла (канадалылар җиңүгә ирешә). Шуннан бирле чемпионатлар ел саен үткәрелә башлый, ә җиңүчеләргә Стэнли кубогы тапшырыла.

смягчения удара. Сегодняшняя сеть объединяет в себе металлическую и веревочную сети.

Первые официальные правила хоккея с шайбой были изданы в 1886 году. Автором кодекса правил стал канадский хоккеист Райан Смит. В том же 1886 году была проведена первая международная встреча между канадской и английской командами (победили канадцы). С тех пор чемпионаты стали проводить ежегодно, а победителям вручать Кубок Стэнли.

***Син беләсеңме?***

*Стэнли кубогы* 1893 елда Канада генерал-губернаторы, британияле лорд Фредерик Артур Стэнли тарафыннан илнең иң яхшы командасын бүләкләү өчен кертелә.

***Знаешь ли ты?***

*Кубок Стэнли* был учреждён в 1893 году генерал-губернатором Канады, британцем лордом Фредериком Артуром Стэнли для награждения лучшей команды страны.

Элек барлык матчлар да ачык һавада үткәрелә, ә беренче *ябык боз мәйданчыклары* бары 1870–1890 елларда гына барлыкка килә. Ябык боз мәйданчыгы табигый бозы булган зур сарай яки ангар рәвешен ала. Салкынны яхшы үткәргәнлектән, бу бина хоккей уйнау өчен бик кулай була.

Уенның барлыкка килүеннән алып 1903 елга кадәр европалылар табигый боз өстендә уйныйлар. Беренче *ясалма боз* Лондонда барлыкка килә, шуннан соң боз мәйданчыкларын камилләштерү һәм яңаларын төзү эше башланып



*Стэнли кубогы*

*Кубок Стэнли*

Сначала все матчи проходили на открытом воздухе, и лишь только в 1870–1890-х годах появились первые *закрытые катки*. Закрытый каток представлял собой большой сарай или ангар с естественным льдом. Такое помещение очень хорошо пропускало холод, благодаря чему можно было играть в хоккей.

С рождения игры вплоть до 1903 года европейцы играли на естественном льду. Первый *искусственный лёд* появился в Лондоне, после чего началось совершенствование катков и строительство новых. Скоро Великобри-

китә. Тиздән Бөек Британия хоккейны профессиональ спорт төре дәрәҗәсенә күтәрә, ләкин озакка түгел… Сугышлар (Беренче бөтендөнья һәм Икенче бөтендөнья сугышлары), башка спорт төрләре белән беррәттән, хоккейга да тискәре йогынты ясый.

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң уен тагын җанланып китә. Хоккейның яңа йолдызлары кабына, яңа хоккей державалары барлыкка килә. XX гасырның икенче яртысында иң көчлеләр булып СССР, Чехословакия һәм Канада җыелма командалары санала.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында мәйданга яңа лидерлар чыга. Шундыйлардан АКШ, Финляндия, Чехия һәм Швеция командаларын атарга мөмкин. Финляндия, Чехия, Швеция һәм Россия җыелма командалары 1996–1997 еллар сезонынннан башлап ел саен Евротур турнирын уздыралар.

тания смогла поднять хоккей на профессиональный уровень, но ненадолго… Войны (Первая мировая и Вторая мировая) на хоккей, как и на все виды спорта, оказали большое негативное влияние.

После Второй мировой войны игра снова возродилась. Загорались новые звезды хоккея, появлялись новые хоккейные державы. Во второй половине XX века сильнейшими командами считались сборные СССР, Чехословакии и Канады.

В конце XX – начале XXI века стали появляться новые лидеры. Таковыми являются команды США, Финляндии, Чехии и Швеции. Сборные Финляндии, Чехии, Швеции и России с сезона 1996–1997 годов проводят ежегодный турнир Евротур.

## Россия хоккееның тарихы

1917 елдан соң илебездә туплы хоккей (рус хоккее, ул «бенди» дип тә атала) популярлаша. Хәтта хатын-кыз командалары да була. Ә шайбалы уенны, нигездә, бу спорт төрен уку программасы кысаларында өйрәнгән физик культура югары уку йорты студентлары уйный.

Россия шайбалы хоккей үсешенең башлану ноктасы дип Бөтенсоюз физик культура комитетының 1946–1947 еллар сезонында шайбалы хоккей буенча СССР чемпионаты үткәрү турындагы карарын санийлар.

Элегрәк ярышларны Бөтенсоюз хоккей секциясе оештырса, 1959 елдан бу эш туплы һәм шайбалы хоккейны берләштергән Хоккей федерациясе карамагына күчә. 1967 елда ул Хоккей федерациясе (шайбалы хоккей) белән Туплы һәм чирәмдәге хоккей федерациясенә бүленә.

## История российского хоккея

После 1917 года в нашей стране особой популярностью пользовался хоккей с мячом (русский хоккей, он же «бенди»). Причём существовали даже женские хоккейные команды. В шайбу же в основном играли студенты физкультурных учебных заведений, изучавшие этот вид спорта в рамках учебной программы.

Точкой отсчёта в развитии отечественного хоккея с шайбой считается решение Всесоюзного комитета по физической культуре и спорту о проведении розыгрыша чемпионата СССР в сезоне 1946–1947 годов.

Сначала соревнования организовывала Всесоюзная секция хоккея, а с 1959 года – Федерация хоккея, объединявшая хоккей с мячом и хоккей с шайбой. В 1967 году она разделилась на Федерацию хоккея (хоккей с шайбой) и Федерацию хоккея с мячом и на траве.

1952 елның 1 апрелендә Советлар Союзының хоккей берләшмәсе Халыкара боздагы хоккей лигасына аяк баса. 1978 елдан бу лига ИИХФ (International Ice Hockey Federation – Шайбалы хоккей халыкара федерациясе) исемен ала.

1 апреля 1952 года хоккейная организация Советского Союза вступила в Международную лигу хоккея на льду, которая с 1978 года называется ИИХФ (International Ice Hockey Federation – Международная федерация хоккея с шайбой).

***Син беләсеңме?***

*Хоккей буенча беренче СССР чемпионаты* 1946 елның 22 декабрендә башланып китә. Беренче шайбаны Мәскәүнең «Динамо» командасы уенчы-тренеры Аркадий Чернышёв кертә. Ә бер айдан, 1947 елның 26 гыйнварында, илнең хоккей буенча беренче чемпионы билгеләнә. Ул «Динамо» (Мәскәү) командасы була.

***Знаешь ли ты?***

*Первый чемпионат СССР по хоккею* стартовал 22 декабря 1946 года. Первую шайбу забросил играющий тренер столичного «Динамо» Аркадий Чернышёв. А через месяц, 26 января 1947 года, определился первый чемпион страны по хоккею. Это была команда «Динамо» (Москва).

Бу еллардагы хоккей хәзерге көн уенын бик аз хәтерләтә. Мәйданчык тәбәнәк һәм бер кагылуга авып китә торган беркетелмәгән фанер бортлар белән әйләндереп алына. Шуңа күрә көч кулланып, көрәшеп уйнау турында сүз алып барырга мөмкин булмый.

Капкачылар телогрейка, мамык чалбар һәм туплы хоккейда кулланыла торган калкан кияләр. Ул вакытта шлем һәм битлекләр кулланылмаган кебек, перчатка-тозаклар да булмый әле. Һәр сезон саен хоккеистларның уйнау техникалары да, экипировкалары да камилләшә.

Илебез хоккее көнләп түгел, сәгатьләп үсә, үзгәрә. 1948 елда совет хоккейчылары Чехословакиянең Прага шәһәреннән килгән ЛТЦ командасы белән халыкара матчлар уздыра. Ул матчлар хоккейчыларыбызның дөньядагы иң яхшы командаларга каршы тора алуларын гына түгел, аларны җиңә алуларын да күрсәтә. Совет хоккейчылары искиткеч шуу техникалары һәм зур тизлектә уйнау-

Хоккей тех лет мало напоминал нынешнюю игру. Площадка была ограничена низенькими и ничем не закреплёнными фанерными бортиками, отъезжавшими в сторону при первом же прикосновении к ним. Ни о какой силовой борьбе у таких бортов и речи идти не могло.

Вратари надевали телогрейки, ватные брюки и щитки, применявшиеся в хоккее с мячом. Перчаток-ловушек для них тогда ещё не было, как и шлемов, и масок. С каждым сезоном техника и экипировка хоккеистов совершенствовались.

Отечественный хоккей развивался не по дням, а по часам. Большим событием стали в 1948 году международные матчи советских хоккеистов с чехословацкой командой ЛТЦ (Прага). Те далёкие матчи показали, что наши хоккеисты могут не только на равных противостоять ведущим командам мира, но и переигрывать их. Советские хоккеисты отличались великолепной техникой катания и вы-

лары белән аерылып торалар. Бу аңлашыла да: аларның күбесе туплы хоккей мәктәбен үтә, ә кайберләре бу вакытта хоккейның ике төрендә дә чыгыш ясый.

1949 елда хоккеистларга беренче тапкыр «Атказанган спорт мастеры» исеме бирелә. Бу дәрәҗәгә Анатолий Тарасов лаек була. Ә 1951 елда ул «Шайбалы хоккей» дигән китап яза. Бу – хоккейга багышланган беренче совет китабы.

сокоскоростной игрой. И это неудивительно – большинство из них прошли школу хоккея с мячом, а некоторые ещё продолжали совмещать выступления и в том, и в другом виде спорта.

В 1949 году впервые звания «Заслуженный мастер спорта» удостоен хоккеист. Им стал Анатолий Тарасов. А в 1951 году он написал первую советскую книгу о хоккее под названием «Хоккей с шайбой».

***Син беләсеңме?***

СССРда *хоккей матчы турында беренче телевизион репортаж* 1951–1952 еллар сезонында ясала.

***Знаешь ли ты?***

*Первый телевизионный репортаж о матче по хоккею* в СССР был проведён в сезоне 1951–1952 годов.

1954 елда илебез хоккейчылары беренче мәртәбә дөнья чемпионатында катнаша һәм җиңүгә ирешә. Лидеры Всеволод Бобров булган Советлар Союзы җыелма командасы хәлиткеч матчта, 7:2 исәбе белән канадаларны тар-мар итеп, чемпион була. Бу елларда җыелма команданы Аркадий Иванович Чернышёв һәм Владимир Кузьмич Егоров җитәкли.

1956 елда илебез командасы беренче тапкыр Италиядәге Кортина д'Ампеццо шәһәрендә булып узган Кышкы Олимпия уеннарында катнаша һәм алтын медальләр яулый. Шул ук елны Мәскәү шәһәрендә илебездәге беренче ясалма боз мәйданчыгы – «Сокольники» җәйге катогы төзелә.

1956 елда Мәскәүдә озак вакытлар дәвамында Советлар Союзының төп хоккей аренасы булачак «Лужники» спорт сарае ачыла. 1957 елның 24 февраленнән 5 мартына кадәр Россиядә беренче тапкыр шайбалы хоккей буенча дөнья чемпионаты үткәрелә.

1963 елда, җидееллык тәнәфестән соң, Советлар Союзы җыелма командасы Швециядә дөнья чемпионы була.

В 1954 году отечественные хоккеисты одержали победу в дебютном для себя чемпионате мира. Сборная Советского Союза, ведомая её непревзойдённым лидером Всеволодом Бобровым, стала чемпионом, разгромив в решающем матче канадцев – 7:2. В эти годы сборную тренировали Аркадий Иванович Чернышёв и Владимир Кузьмич Егоров.

В 1956 году отечественная сборная впервые принимает участие в Зимних Олимпийских играх в Кортина д'Ампеццо (Италия) и завоёвывает золотые медали. В этом же году в Москве строится первый в стране каток с искусственным льдом – летний каток «Сокольники».

В 1956 году открыт Дворец спорта в Лужниках (Москва), долгие годы являвшийся главной хоккейной ареной Советского Союза. С 24 февраля по 5 марта 1957 года в России впервые проводился чемпионат мира по хоккею с шайбой.

После семилетнего перерыва в 1963 году в Швеции сборная Советского Союза стала чемпионом мира.

Бу җиңүдән соң безнең җыелма команда тугыз ел буе дөнья пьедесталының иң югары баскычыннан төшми.

1964 елда Австриянең Инсбрук шәһәрендә Кышкы Олимпия уеннары кысасында үткән хоккей турниры совет хоккейчыларының җиңүе белән тәмамлана.

1964 елның 8 декабрендә «Алтын шайба» исемле балалар хоккей турнирына нигез салына. Нәкъ менә бу ярышлар илебез хоккеена дөнья аренаЛарында җемелдәп торучы якты йолдызлар бүләк итә.

После этой победы наша сборная в течение девяти лет оставалась на высшей ступени мирового пьедестала.

Хоккейный турнир в рамках Зимних Олимпийских игр 1964 года в Инсбруке (Австрия) завершился победой советских хоккеистов.

8 декабря 1964 года родился популярнейший детский хоккейный турнир «Золотая шайба». Именно эти соревнования дали отечественному хоккею многих звёзд, заблиставших на ледовых аренах всего мира.

***Син беләсеңме?***

*«СССРның халыкара класслы спорт мастеры» исеме* 1965 елның 1 гыйнварында гамәлгә кертелә. Беренчеләрдән булып аңа Финляндиядә оештырылган дөнья чемпионатында кабат беренчелекне яулап кайткан совет җыелма командасы хоккеистлары лаек була.

***Знаешь ли ты?***

*Звание «Мастер спорта СССР международного класса»* было учреждено 1 января 1965 года. Первыми его удостоились хоккеисты советской сборной, в очередной раз победившие на чемпионате мира в Финляндии.

1968 елда Франциянең Гренобль шәһәрендә үткәрелгән Олимпия уеннарында безнең хоккеистлар өченче тапкыр алтын медальләр яулый.

1969 елның 10–12 октябрендә ЦСКА хоккейчылары, Австриянең «Клагенфурт» клубын җиңеп (9:1, 14:3), Европа чемпионнары кубогына ия була.

1972 елның февралендә Японияненң Саппоро шәһәрендә СССР җыелма командасы кабат Олимпия алтынына лаек була.

1973 елның 31 мартыннан 15 апреленә кадәр Мәскәүдә икенче тапкыр дөнья чемпионаты үтә. Ярышлар СССР командасының җиңүе белән тәмамлана.

1976 елның февралендә СССР җыелма командасы Австриянең Инсбрук шәһәрендә кышкы Олимпия уен-

В 1968 году во французском Гренобле сборная СССР в третий раз завоёвывает золотые олимпийские медали.

10–12 октября 1969 года в Австралии хоккеисты ЦСКА завоевали Кубок европейских чемпионов, победив местный «Клагенфурт» (9:1, 14:3).

В феврале 1972 года сборная СССР в очередной раз выиграла олимпийское золото в японском Саппоро.

31 марта – 15 апреля 1973 года чемпионат мира по хоккею во второй раз принимала Москва. Соревнования завершились победой сборной СССР.

В феврале 1976 года сборная СССР становится победителем хоккейного турнира в рамках зимних Олимпийских игр в Инсбруке (Австрия).

нары кысаларында үткәрелгән хоккей турнирының җиңүчесе була.

1978 елда СССР җыелма командасы янәдән дөнья чемпионы титулына ия була.

1979 елның 14–27 мартында дөнья чемпионаты өченче тапкыр Мәскәүдә үтә, һәм СССР җыелма командасы тагын алтын медальләр яулый.

1984 елның февралендә Югославиянең Сараево шәһәрендә үткәрелгән Олимпия уеннарында совет хоккейчылары җиңүгә ирешә.

1986 елның апрелендә Мәскәү шәһәрендә дөнья чемпионаты дүртенче тапкыр уздырыла. Советлар Союзы командасы егерменче мәртәбә планетаның иң көчле командасы булып таныла.

1988 елның февралендә совет хоккейчылары Канаданың Калгари шәһәрендә үткән Олимпия уеннарында җиңүче була.

1992 елның февралендә илебез җыелма командасы Франциянең Альбервилль шәһәрендә үткәрелгән Олимпия уеннарында сигезенче тапкыр җиңү яулый.

1992–1993 еллар сезонында Милләтара хоккей лигасы (МХЛ) оеша. Шул исем астында үткән беренче чемпионатта Россиядән унтугыз, Казакъстаннан ике, Белоруссия, Латвия һәм Украинадан берәр клуб катнаша.

1993 елда Борис Михайлов җитәкчелегендәге Россия җыелма командасы Германиядә үткән дөнья чемпионатында егерме өченче тапкыр алтын медальләр яулый.

В 1978 году сборная СССР снова завоевала титул чемпионов мира.

14–27 марта 1979 года в третий раз чемпионат мира принимала Москва. Сборная СССР вновь завоевала золотые медали.

Февраль 1984 года – победа советских хоккеистов на Олимпиаде в Сараево (Югославия).

В апреле 1986 года в четвёртый раз чемпионат мира проводится в Москве. Сборная Советского Союза в двадцатый раз стала сильнейшей на планете.

Февраль 1988 года – победа советской хоккейной команды на Олимпиаде в Калгари (Канада).

Февраль 1992 года – сборная нашей страны в восьмой раз побеждает на Олимпиаде в городе Альбервилль (Франция).

В сезоне 1992–1993 годов организована Межнациональная хоккейная лига (МХЛ). Первый чемпионат страны под этим именем прошёл с участием девятнадцати клубов, представлявших Россию, двух из Казахстана и по одному из Белоруссии, Латвии и Украины.

В 1993 году на чемпионате мира в Германии сборная России под руководством Бориса Михайлова стала обладателем двадцать третьих золотых медалей.

***Син беләсеңме?***

*Хатын-кызлар хоккееның үсеше турында карар* Россиянең Олимпия комитеты тарафыннан 1994 елда кабул ителә. Сентябрь аенда Россиянең хатын-кызлар җыелма командасы үзенең беренче матчын уздыра.

***Знаешь ли ты?***

*Решение о развитии женского хоккея* в стране было принято Олимпийским комитетом России в 1994 году. В сентябре женская сборная России провела свой первый матч.

1996 елда Ярославль шәһәрендә хатын-кызлар арасында Европа чемпионаты үтә. Россия җыелма командасы, беренче урын алган Швеция спортсменнарыннан гына калышып, көмеш медальләр яулый. Шул ук елда Россия хоккей лигасына (РХЛ) нигез салына. Ул МХЛны алыштыра. РХЛга Россия Федерациясе шәһәрләреннән килгән командалар керә.

1998 елның февралендә Япониянең Нагано шәһәрендә үткәрелгән кышкы Олимпия уеннарында Владимир Юрзинов җитәкчелегендәге Россия җыелма командасы көмеш медальләр яулый.

1999–2000 еллар сезонында РХЛ бетерелә, аның урынына Профессиональ хоккей лигасы (ПХЛ) оеша.

1999 елның 10 декабрендә Новокузнецк шәһәрендә Россиядә беренче тапкыр «Барлык йолдызлар» матчы уза.

2000 елның 29 апреленнән 14 маена кадәр Санкт-Петербургта дөнья чемпионаты үткәрелә. Күбесенчә Милли хоккей лигасы уенчыларыннан тупланган турнир хуҗалары унберенче урынны гына ала.

2001 елда Россиянең хатын-кызлар җыелма командасы дөнья чемпионатында беренче тапкыр медальләр яулый. Безнең кызларны бары тик Канада һәм АКШ спортчылары гына уза.

2002 елның гыйнварында Владимир Плющев җитәкчелегендәге Россия яшьләр җыелма командасы дөнья чемпионатында җиңү яулый. Бу илебез яшьләренең унберенче алтыны була.

2002 елның февралендә АКШның Солт-Лейк-Сити шәһәрендә узган Олимпия уеннарында Россия җыелма командасы өченче урынны ала.

2002 елның маенда, тугыз еллык тәнәфестән соң, Россия хоккейчылары дөнья чемпионатының көмеш медальләренә ия була.

2003 елда Канаданың Галифакс шәһәрендә үткәрелгән дөнья чемпио-

В 1996 году в Ярославле прошёл чемпионат Европы среди женщин. Сборная России завоевала серебряные медали, уступив первое место шведским спортсменкам. В этом же году создана Российская хоккейная лига (РХЛ), заменившая МХЛ. В РХЛ вошли клубы, представлявшие города Российской Федерации.

Февраль 1998 года – в зимних Олимпийских играх в Нагано (Япония) сборная России под руководством Владимира Юрзинова завоевала серебряные медали.

В сезоне 1999–2000 годов РХЛ была заменена Профессиональной хоккейной лигой (ПХЛ).

10 декабря 1999 года в Новокузнецке впервые в России состоялся матч «Всех звёзд».

29 апреля – 14 мая 2000 года чемпионат мира принимал Санкт-Петербург. Хозяева турнира, представленные в основном игроками Национальной хоккейной лиги, заняли лишь одиннадцатое место.

В 2001 году женская сборная России по хоккею впервые завоевала медали чемпионата мира. Впереди наших девушек оказались только представительницы Канады и США.

Январь 2002 года – победа молодёжной сборной России на чемпионате мира под руководством Владимира Плющева. Это одиннадцатое золото «молодёжки» нашей страны.

Февраль 2002 года – на Олимпиаде в Солт-Лейк-Сити (США) сборная России заняла третье место.

Май 2002 года – после девятилетнего перерыва медали чемпионатов мира (серебро) завоевали российские хоккеисты.

В 2003 году молодёжная сборная России завоевала золотые медали (двенадцатые по счёту) чемпионата мира на льду канадского Галифакса.

натында Россиянең яшьләр җыелма командасы уникенче тапкыр алтын медальләр яулый. Җиңүчеләрнең баш тренеры Рафаил Ишматов була.

2004 елның апрелендә Россиянең юниорлар (18 яшькә кадәр) җыелма командасы Белоруссиянең Минск шәһәрендә үткәрелгән дөнья чемпионатында алтын медальләр яулый.

2005 елның 4 гыйнварында Сергей Герсонский җитәкчелегендәге Россия җыелма командасы АКШта узган дөнья чемпионатында көмеш медальләргә ия була.

2005 елның 22–24 апрелендә Владимир Крикунов җитәкчелегендәге Россия җыелма командасы, финалның ике уенында Швеция спортсменнарын отып, Еврохоккейтурның абсолют җиңүчесе була.

2005 елның 30 апреленнән 15 маена кадәр Австриянең Вена һәм Инсбрук шәһәрләрендә узган дөнья чемпионатында Россия хоккейчылары өченче урын алалар.

2006 елның маенда Россия хоккейчылары Еврохоккейтурның иң көчле командасы титулына ия була.

2006 елның 5–21 маенда Латвиянең Рига шәһәрендә хоккей буенча дөнья чемпионаты уздырыла. Россия җыелма командасы монда бары тик бишенче урынны гына ала.

Главным тренером победителей был Рафаил Ишматов.

В апреле 2004 года сборная юниоров России (до 18 лет) завоевала золотые медали чемпионата мира, проходившего в Минске (Белоруссия).

4 января 2005 года молодёжная сборная России под руководством Сергея Герсонского на чемпионате мира, проходившего в США, стала обладателем серебряных медалей.

22–24 апреля 2005 года сборная России под руководством Владимира Крикунова впервые в истории отечественного хоккея стала абсолютным победителем Еврохоккейтура, переиграв в двух финальных матчах команду Швеции.

30 апреля – 15 мая 2005 года на чемпионате мира в Австрии (Вена, Инсбрук) российские хоккеисты финишировали на третьем месте.

В мае 2006 года российские хоккеисты завоевали титул сильнейшей команды Еврохоккейтура.

5–21 мая 2006 года – чемпионат мира по хоккею в Латвии (Рига). Команда России заняла здесь лишь пятое место.



*Александр Овечкин*

***Син беләсеңме?***

Россия җыелма командасының һөҗүмчесе *Александр Овечкин,* дөнья хоккее тарихында беренчеләрдән булып, Олимпия турниры (Италия) һәм дөнья чемпионатының (Латвия) символик җыелма командалары составына кертелә.

***Знаешь ли ты?***

Нападающий сборной России *Александр Овечкин* стал первым игроком в истории мирового хоккея, который был включён в символические сборные на олимпийском турнире (Италия) и чемпионате мира (Латвия).

2006–2007 еллар сезонынннан башлап хоккей буенча бөтен ярышларны Россиянең хоккей федерациясе уздыра.

2008 елда илебезнең җыелма командасы дөнья чемпионатының алтын медальләрен яулый.

2008 елда, Гагарин кубогы беренчелеген үткәрү өчен, Евразиядәге ачык халыкара хоккей лигасы – Континенталь хоккей лигасына (КХЛ) нигез салына. КХЛ Россия хоккееның суперлигасы нигезендә оеша һәм үз эченә егерме дүрт клубны ала. 2008–2009 еллар сезонында әлеге лигада Россиядән егерме бер, Белоруссия, Латвия һәм Казакъстаннан берәр команда катнаша.

2009 елның 12 апрелендә Казанның «Ак Барс» командасы КХЛ чемпионы исемен ала һәм хоккей тарихында беренчеләрдән булып Гагарин кубогына ия була.

2009 елда Россиянең җыелма командасы, финалда Канада командасын җиңеп, дөнья чемпионатының алтын медальләрен яулый.

С сезона 2006–2007 годов все соревнования по хоккею в нашей стране проводит Федерация хоккея России.

2008 год – золотые медали чемпионата мира в копилке нашей сборной.

В 2008 году для проведения первенства на Кубок Гагарина была создана Континентальная хоккейная лига (КХЛ) – открытая международная хоккейная лига в Евразии. КХЛ создана на основе Российской хоккейной суперлиги и включает в себя двадцать четыре клуба. В сезоне 2008–2009 годов в лигу вошли двадцать один клуб из России, а также по одному клубу из Белоруссии, Латвии и Казахстана.

12 апреля 2009 года команда «Ак Барс» (Казань) стала первым обладателем Кубка Гагарина и чемпионом КХЛ в истории хоккея.

В 2009 году сборная России по хоккею завоевала золотые медали чемпионата мира, обыграв в финале канадскую сборную.



*Россия җыелма командасы* *Сборная команда России*

# Уен кагыйдәләре

- Мәйданчык
- Капка һәм капка мәйданчыгы
- Кәшәкә һәм шайба
- Уенчының экипировкасы
- Уен барышы
- Команда составы
- Казыйлар
- Кагыйдә бозу очраклары һәм штрафлар
- Ярышлар формуласы

# Правила игры

- Площадка
- Ворота и площадь ворот
- Клюшка и шайба
- Экипировка игрока
- Ход игры
- Состав команды
- Судьи
- Нарушение правил и штрафы
- Формула соревнований

*Хоккей матчыннан чираттагы репортажны караганда яки яраткан командаңның уенын трибунадан күзәткәндә, син бу спорт төренең авырлыгын ахыргача аңлап та бетермисеңдер. Чөнки хоккей җанатарларга ләззәт, ә уенчыларга илһам бирә торган матур уен гына түгел. Ул, беренче чиратта, үз кагыйдәләре һәм үз нечкәлекләре булган фән.*

*Смотря очередной репортаж с хоккейного матча или наблюдая за игрой любимой команды с трибуны, ты, наверное, не до конца понимаешь сложность этого вида спорта. Ведь хоккей – это не просто красивая игра, которая доставляет удовольствие болельщикам и вдохновляет игроков. Это, прежде всего, наука со всеми своими правилами и особенностями.*

***Исеңдә тот!***

*Хоккей* – махсус боз мәйданчыгында кәшәкәләр һәм шайба кулланып уйнала торган командалы спорт уены. Уенның *максаты* – шайбаны көндәшләр капкасына кертү. Матчта күбрәк алка керткән команда җиңүче була.

***Запомни!***

*Хоккей* – это спортивная командная игра с клюшками и шайбой на специальной ледяной площадке. *Цель* игры – забить шайбу в ворота соперника. В матче побеждает команда, забросившая больше шайб.

Хоккей кагыйдәләре еллар дәвамында бик күп һәм бик җитди үзгәрешләр кичерә. Мәсәлән, XIX гасырда мәйданчыктагы хоккейчыларның саны тугызга тугыз, соңрак җидегә җиде була. Уенчылар алышынмыйча уйный, ә команда составына бүгенге көн өчен гадәти булмаган амплуалы хоккейчылар керә. Мәсәлән, *ровер* (ингл. *rover* – сукбай, зимагур) – көндәшләр капкасы янында гына уйнау хокукы булган һөҗүмче.

Шайба (алка) уенга башкача кертеп җибәрелгән. Казый алканы бозга куйган һәм тиешле боерык биргәннән соң гына читкә киткән. Еллар узу белән генә шайбаны ата башлыйлар.

Озак вакытлар дәвамында көч кулланып уйнау бары тик саклану зонасында гына рөхсәт ителә. 1970 елдан гына мәйданчыкның бар җирендә дә көч кулланырга мөмкин дип табыла.

Иң зур үзгәрешләрнең берсе 2001 елда ясала: «кызыл сызык кагыйдә-

В течение многих лет хоккейные правила не раз менялись, причём весьма существенно. Например, в XIX веке количество игроков на площадке было иным (девять на девять, затем – семь на семь). Игроки играли без замен, а в составе команд были хоккеисты с необычным по современным меркам амплуа. Например, так называемый *ровер* (англ. *rover* – бродяга, скиталец) – нападающий, имевший право играть только у ворот соперника.

По-иному вводилась в игру шайба. Судья клал её на лёд и, подав соответствующую команду, отскакивал в сторону. Лишь со временем шайбу стали вбрасывать.

Долгое время применение силовых приёмов допускалось исключительно в зоне защиты. Только в 1970 году разрешили силовую борьбу по всему полю.

Одно из самых кардинальных изменений произошло в 2001 году: было отменено так называемое «правило

се» кире кагыла. Уенчының, бу кагыйдә буенча, саклану зонасыннан атылып, урта зонаны узган шайбаны кабул итәргә хокукы булмый.

Мондый яңарышлар уенны хәрәкәтлерәк, үткенрәк һәм карарга кызыграк итү өчен кертелә.

красной линии», по которому игрок не мог принимать шайбу за средней линией, если она была послана из зоны защиты.

Подобные новшества вносятся в правила для того, чтобы сделать игру более динамичной, острой и зрелищной.

## Мәйданчык

*Мәйданчык* тигез боз өслекле турыпочмаклыктан гыйбарәт. Мәйданчыкның *озынлыгы* 56–61 м, *киңлеге* 26–30 м (Төньяк Америка мәйданчыклары таррак).

## Площадка

*Площадка* представляет собой прямоугольник с ровной ледяной поверхностью. *Длина* площадки – 56–61 м, *ширина* – 26–30 м (в Северной Америке площадки уже).




*Мәйданчык* *Площадка*

Мәйданчык 1,20–1,22 м озынлыктагы, кырыйлары түгәрәкләнгән (радиусы 7–8,5 м) *бортчык* белән әйләндереп алына.

Тышкы (капка артындагы) бортлардан 4 м ераклыкта, аркылыга *кызыл капка сызыклары* үткәрелгән. Бу сызыкларга параллель рәвештә (алардан 10 м ераклыкта) *зәңгәр сызыклар* билгеләнгән, алар мәйданчыкны

Площадка ограждена *бортиком* высотой 1,20–1,22 м, имеющим закругления (радиусом 7–8,5 м).


В 4 м от лицевых бортов поперёк поля проведены *красные линии ворот*. Параллельно этим линиям (на расстоянии 10 м от них) обозначены *синие линии*, которые делят площадку на три зоны: *зону защиты*, *среднюю зону* и *зону нападения*. *Средняя*

өч зонага бүлә: *саклану зонасы, урта зона* һәм *һөҗүм итү зонасы. Урта сызык* мәйданчык аркылы үткәрелә һәм аны ике тигез өлешкә бүлә. Мәйданчыкның үзәгендә (урта сызыкта) *үзәк нокта* билгеләнә, бу ноктада һәрбер период башында һәм капка алынганнан соң, шайба атыла. Шайбаны ату нокталары шулай ук ике якта, капкадан 6 м ераклыкта, һәм урта зонада, зәңгәр сызыклардан 1,5 м ераклыкта билгеләнгән. Капка янындагы шайба ату нокталары (яки *ахыргы шайба ату нокталары*) һәм үзәк нокта тирәсендә радиусы 4,5 м булган әйләнә үткәрелгән.

Боз өстендә, казый өстәле янында, радиусы 3 м булган ярымтүгәрәк рәвешендәге махсус зона билгеләнгән: ул *казый мәйданчыгы* дип атала. Баш казый башка казыйларга нәрсәдер хәбәр иткәндә яки алар белән теге яки бу уен моменты турында киңәшләшкәндә, хоккейчыларның бу зонада булырга хокукы юк.

*линия* проводится поперёк поля и делит его на две равные части. В центре площадки (на средней линии) обозначается *центральная точка*, на которой вбрасывается шайба в начале каждого периода, а также после взятия ворот. Точки вбрасывания обозначены также по обе стороны от ворот на расстоянии 6 м от линии ворот и в средней зоне на расстоянии 1,5 м от синих линий. Вокруг точек вбрасывания у ворот (или *точек конечного вбрасывания*) и вокруг центральной точки очерчен круг радиусом 4,5 м.

У судейского столика на льду обозначена специальная зона в виде полукруга радиусом 3 м – так называемая *судейская площадь*. Хоккеисты не имеют права находиться там в момент, когда главный судья сообщает что-либо или консультируется с кем-то из судей по той или иной игровой ситуации.



*Мәйданчыкның схемасы* *Схема площадки*

## Капка һәм капка мәйданчыгы

Капка рамы ике вертикаль терәктән һәм аларны тоташтыручы кызыл төстәге горизонталь өрлектән гыйбарәт. Капканың *биеклеге* (боз өслегеннән өрлеккә кадәр) 122 см, *киңлеге* (эчке озынлыгы) 183 см.

Вертикаль терәкләрдә штырьлар (кире чыкмасын өчен очы сырлы итеп эшләнгән кадаклар) бар, алар капкаларның бер урында торуына булышлык итәләр. Капканы бозга катырып кую тыела. Сакланучы команда уенчысы капканы юри урыныннан кузгатса, аңа штраф салына.

Капка алдында кызыл сызык белән капка мәйданчыгы билгеләнә (гадәттә ул ярымтүгәрәк рәвешендә була). Капка мәйданын чикләүче сызыклар аның бер өлеше булып санала.

## Ворота и площадь ворот

Рамка ворот состоит из двух вертикальных стоек и соединяющей их горизонтальной перекладины красного цвета. *Высота* ворот (от поверхности льда до перекладины) – 122 см, *ширина* (внутренний размер) – 183 см.

Вертикальные стойки имеют штыри, они позволяют фиксировать ворота на одном месте. Примораживать ворота ко льду запрещено. Если игрок обороняющейся команды умышленно сдвигает ворота с места, на него накладывается штраф.

Перед воротами красной линией очерчивается площадь ворот (обычно в виде полукруга). Линии, ограничивающие площадь ворот, считаются её частью.



*Капка*



*Ворота*

## Кәшәкә һәм шайба (алка)

*Шайба* резинадан эшләнгән кара төстәге каты яссы дисктан гыйбарәт. Алканың *биеклеге* 2,54 см, *диаметры* 7,62 см, *авырлыгы* 156–170 г.

## Клюшка и шайба

*Шайба* представляет собой плоский твёрдый диск из резины преимущественно чёрного цвета. *Высота* шайбы – 2,54 см, *диаметр* – 7,62 см, *масса* – 156–170 г.

***Исеңдә тот!***

*Шайба* уенга бары бер юл белән – атып кертелә. Кагыйдә буенча, шайба бозга төшеп җитмичә, уенчыларның аңа кагылырга хокукы юк.

***Запомни!***

*Шайба* вводится в игру одним-единственным способом – вбрасыванием. По правилам, игроки не имеют права касаться шайбы, пока она не коснется льда.



*Алка* *Шайба*



*Уенчы кәшәкәсе*

*Клюшка игрока*

Хоккей *кәшәкәсе* ыргак һәм саптан (таяктан) тора. Аның үкчәсеннән (сап белән ыргакның тоташкан урыныннан) сабының башына кадәр *озынлыгы* 163 см, үкчәдән ыргак башына кадәр 32 см. Сапның *максималь киңлеге* 3 см, *калынлыгы* 2,5 см. Ыргакның *киңлеге* 5 см дан да ким һәм 7,5 см дан да озынрак булмаска тиеш. Капкачы кәшәкәсе ыргагының һәм сабының *максималь киңлеге* 9 см, үкчәсенеке – 11,5 см. Аның ыргагы башка уенчылар кәшәкәсе ыргагыннан киңрәк кенә түгел, озынрак та – 39 см. Кәшәкәләр агачтан һәм башка материаллардан эшләнә. Аларның теләсә кайсы урыны изолента белән чорналырга мөмкин.

Хоккейная *клюшка* состоит из крюка и ручки (палки). *Длина* её от пятки (места соединения ручки с крюком) до конца ручки – 163 см, от пятки до конца крюка – 32 см. *Максимальная ширина* ручки – 3 см, *толщина* – 2,5 см. *Ширина* крюка должна быть не менее 5 и не более 7,5 см. *Максимальная ширина* крюка и ручки вратарской клюшки – 9 см, а в пятке – 11,5 см. Крюк её не только шире, но и длиннее, чем у клюшки полевого игрока – 39 см. Клюшки изготавливаются из дерева и других материалов. Они могут быть обмотаны изолентой в любой части.



*Капкачы кәшәкәсе*

*Клюшка вратаря*

*Ыргак* бөгелешенең тирәнлеге 1,5 см дан артмаска тиеш. Уенчы стандартка туры килмәгән зурлыктагы кәшәкә кулланса, аңа штраф салына. Еш кына рефери (баш казый) кәшәкәне каршы як командасы таләбе буенча үлчи. Әгәр стандартлардан читкә чыгу күзәтелсә, гаепле уенчыга кече штраф салына.

Глубина загиба *крюка* не должна превышать 1,5 см. За использование клюшки нестандартного размера на игрока налагается штраф. Нередко соответствующие замеры производит рефери (главный судья) по требованию команды-соперницы. В случае, если выявлено отклонение от стандарта, виновный игрок наказывается малым штрафом.

***Исеңдә тот!***

*Сынган кәшәкә* белән уйнау тыела. Уенчы, кәшәкәсенең барлык сынган өлешләрен бозга ташлаганнан соң гына, уенын дәвам итә ала.

***Запомни!***

Запрещается игра *сломанной клюшкой*. Хоккеист, у которого сломалась клюшка, может продолжить участие в игре при условии, что он бросит на лёд все сломанные части клюшки.

## Уенчының экипировкасы

Уенчының экипировкасына (кәшәкәдән кала) тимераяклар, махсус кием (униформа) һәм саклагыч амуниция (хоккейчының кәшәкәдән һәм киемсалымнан башка кирәк-яраклары) керә.

*Хоккей униформасы* свитер, хоккей шортигы һәм шлемнан гыйбарәт (шлем шулай ук саклагыч вазифаны үти). Уенчының свитеры һәм шортигына номер язылa. Ул кабул ителгән зурлыкта һәм кием төсенә контраст төстә булырга тиеш. (Кайбер уенчылар үзләренә гадәти булмаган номер алырга яратканга, ИИХФ махсус чикләү кертергә мәҗбүр була: хоккейчыларның номерлары 1 дән 99 га кадәр төрләнә ала.) Свитерның артына уенчының фамилиясе дә языла. Капитан кигән свитерның алгы ягына «С» хәрефе (ингл. *captain* – капитан), ә ярдәмчеләренең свитерларына «А» хәрефе (ингл. *assistant* – ассистент) төшерелә.

Әгәр көндәш командаларның киемнәре төсләре белән охшаш булса,

## Экипировка игрока

В экипировку игрока (помимо клюшки) входят коньки, униформа и защитная амуниция (другие приспособления хоккеиста кроме клюшки и формы).

*Хоккейная униформа* состоит из свитера, трусов и шлема (выполняющего также защитную функцию). На свитере и трусах игрока обозначается его номер. Он должен быть установленного размера и цвета, контрастного цвету самой формы. (Поскольку многие игроки любят выбирать необычные номера, ИИХФ ввела специальное ограничение: номера хоккеистов варьируются в пределах от 1 до 99.) Сзади на свитере указывается и фамилия игрока. Спереди на свитере капитана нашивается также буква «С» (от англ. *captain* – капитан), а на свитерах его помощников – «А» (англ. *assistant* – ассистент).

Если форма команд-соперниц настолько схожа по цвету, что это мо-



*Уенчының экипировкасы*



*Экипировка игрока*

һәм бу уен процессында буталчыклык китереп чыгарса (мәсәлән, гол кертүче яисә кагыйдә бозучыны билгеләгәндә), «хуҗа» команда рефери таләбе буенча формасын алыштырырга тиеш. Формадагы бертөрлелек кагыйдәсе уенчыларның шлемнарына да кагыла, бары капкачы гына башка уенчыларныкына охшамаган төстәге шлем кия ала.

Хоккейчының *саклагыч амунициясе шлем, перчаткаларны* һәм шулай ук форма өстеннән киелә торган *тез саклагычларны, терсәк саклагычларны, калканны* (кечкенә щит) һ.б. үз эченә ала. ИИХФ исеме астында үткәрелә торган матчларда уенчылар халыкара стандартларга туры килә торган һәм кагыйдә буенча дөрес итеп каптырылган саклагыч шлемнар киеп

жет привести к путанице в процессе игры (например, при определении взятия ворот или фиксации нарушения правил), то команда-«хозяйка» по требованию рефери должна сменить форму. Требование цветового единообразия формы распространяется и на шлемы игроков. Только вратарь может носить шлем, отличный по цвету от шлемов полевых игроков.

*Защитная амуниция* хоккеиста включает *шлем*, *перчатки*, а также надеваемые под форму *наколенники*, *налокотники*, *щитки* и пр. приспособления. В матчах, проводимых под эгидой ИИХФ, игроки могут выступать только в защитных шлемах, отвечающих международным стандартам и застёгнутых в соответствии с правилами. Если хоккеист в процес-

уйнарга тиеш. Хоккейчы уен вакытында мәйданчыкка каптырылмаган каешлы шлем киеп чыкса, аңа кече штраф салына.

Голкипер (капкачы) экипировкасына битне тулысынча каплый торган *капкачы битлеге*, форма өстеннән аякка киелә торган (киңлеге 30 см дан узмаган) *калканнар*, *перчатка-тозак* һәм голкиперның кәшәкә тоткан кул чугын каплый торган *калкан* (блин) керә. Калкан һәм тозакның *киңлеге* 21 см дан, ә *биеклеге* 42 см дан артмаска тиеш.

се игры появляется на площадке в шлеме с незастегнутым ремешком, он наказывается малым штрафом.

В экипировку голкипера входят также *вратарская маска*, целиком закрывающая лицо, надеваемые на ноги поверх формы *щитки* (шириной не более 30 см), *перчатка-ловушка* и *щиток* (блин), закрывающий кисть руки, в которой голкипер держит клюшку. *Ширина* щитка и ловушки не может превышать 21 см, а *высота* – 42 см.




*Капкачы* *Вратарь*

***Исеңдә тот!***

Халыкара кагыйдәләр буенча 20 яшькә кадәр уенчыларның барысы да *махсус битлекләр* киеп уйнарга тиеш (аларны еш кына «битлекчеләр» дип тә атыйлар). Мондый битлекләрне индивидуаль рәвештә зуррак яшьтәге хоккейчылар да кия ала.

!

***Запомни!***

Международными правилами предусмотрены *специальные маски* для полевых игроков моложе 20 лет (их нередко так и называют – «масочники»). Такие маски могут в индивидуальном порядке использовать и хоккеисты старшего возраста.

## Уен барышы

Хоккей матчы чиста уен вакытының 60 минутын – араларында 15 минутлык тәнәфесе булган 20 минутлы 3 периодны үз эченә ала. Уен вакытын *казый-хронометрист* саный. Һәр периодтан соң көндәшләр капкаларын алыштыралар. Командалар матч дәвамында берәр *тайм-аут* (ингл. *time-out* – тәнәфес) алырга мөмкин: бу төп яки өстәмә вакытта, бары тик уен туктап торганда гына эшләнә.

Ярышлар регламенты буенча, уен тигез исәпкә бетә алмаса, 5, 10 яки 20 минутлык өстәмә период – *овертайм* (ингл. *overtime* – эш сәгатеннән соң булган вакыт) билгеләнә. Уен беренче голга (хоккей жаргонында – «көтелмәгән үлем») кадәр дәвам итә. Кайбер ярышларда, әгәр овертаймда да җиңүче ачыкланмаса, ничья билгеләнә, һәм көндәшләр берәр очко ала (төп вакытта җиңү яулаган команда 3, овертаймда отканы 2 очкога лаек була, төп вакытта җиңелгәннәр бер очко да алмый). Дөнья чемпионатларында (плей-офф стадиясендә) мондый очракта матчтан соң буллитлар сериясе атыла. Стэнли кубогы ярышларында исә овертаймда уен һәрвакыт беренче голга кадәр дәвам итә (бу вакытта өстәмә периодларның саны да, матчның гомуми озынлыгы да исәпкә алынмый).

## Ход игры

Хоккейный матч продолжается 60 минут чистого игрового времени: 3 периода по 20 минут каждый с 15-минутными перерывами между ними. Отсчёт игрового времени ведёт *судья-хронометрист*. После каждого периода соперники меняются воротами. Команды имеют право на протяжении матча взять по одному *тайм-ауту* (англ. *time-out* – перерыв) в основное или в дополнительное время, но только во время остановки в игре.

В случае, если регламентом соревнований ничейный исход в матче исключён, назначается дополнительный период – *овертайм* (англ. *overtime* – сверхурочное время) продолжительностью 5, 10 или 20 минут. Игра ведётся до первого гола (на хоккейном жаргоне – «внезапная смерть»). На некоторых соревнованиях, если и в овертайме не выявлен победитель, фиксируется ничья, и соперники получают по одному очку (победа в основное время приносит, соответственно, 3 очка, в овертайме – 2, проигравшая команда в основное время очков не получает.) На чемпионатах мира (в стадии плэй-офф) в подобной ситуации пробивается серия послематчевых буллитов. А в розыгрыше Кубка Стэнли игра в овертайме в любом случае продолжается до первого гола – вне зависимости от количества сыгранных дополнительно периодов и общей продолжительности матча.



*Уеннан бер күренеш*

*Момент из игры*

## Команда составы

Һәр командадан матчка егерме икегә кадәр хоккейчы (егерме уенчы һәм ике капкачы) тәкъдим ителә ала.

Уен вакытында мәйданчыкка һәр командадан алты хоккейчы чыга (әгәр бер яки берничә уенчыга штраф салынган булса, мәйданчыктагы партнёрларның саны биштән яки дүрттән артмаска тиеш). Составның саны бозылган очракта, командага кече эскәмия штрафы (эскәмиядә 2 минут утыру) салына.

## Состав команды

На матч от каждой команды может быть заявлено не более двадцати двух хоккеистов (двадцать полевых игроков и два вратаря).

В момент игры на площадке могут находиться не более шести хоккеистов одной команды (в случае, если один или несколько игроков команды отбывают наказание на скамейке для оштрафованных, число их партнёров, находящихся на поле, не может превышать пяти или четырёх). Нарушение численного состава карается малым скамеечным штрафом (отбывание наказания на скамейке оштрафованных в течение 2 минут).

## Казыйлар

Уен барышын боз өстендә *рефери* (яки баш казый) һәм *аның ике ярдәмчесе* күзәтеп тора. Алар униформа (кара чалбар һәм аклы-каралы буйлы свитер), тимераяклар кияләр, ә күптән түгел генә әлеге киемнәргә кара төстәге хоккей шлемы да

## Судьи

На льду ход игры контролируют *рефери* (или главный судья) и *два его помощника*. Они носят униформу (чёрные брюки и чёрно-белый полосатый свитер), коньки, а с недавнего времени и чёрный хоккейный шлем. Рефери осуществляет общий контроль



*Казыйлар* *Судьи*

өстәлде. Рефери, гомумән, уен барышын контрольдә тота. Аның карары хәлиткеч була. Казыйның ярдәмчеләре проброс (ыргытып тидерә алмау), «уеннан тыш» халәтне һәм хоккейстчыларның яки шайбаның теге яки бу зонада урнашуы белән бәйле төрле уен моментларын билгелиләр (рефери ярдәмчеләрен инглизчә нәкъ шулай атыйлар да: *linesmen* – сызыктагы кешеләр).

Казый бригадасына шулай ук *капка алынуын билгели торган ике казый* (һәр яктан берәү); *уенның исәбен билгели торган казый* (бер яки ике ярдәмчесе белән); *казый-хронометрист, казый-информатор, штраф салынган уенчылар эскәмиясендәге казыйлар,* шулай ук *уенны видеога төшерүне тәэмин итүче казый* керә. Капка алыну белән бәйле бәхәсле ситуациядә рефери, хәлиткеч карар чыгару алдыннан, уен видеоязмасының кирәкле фрагментын карый ала.

Матч вакытында команда капитаны яки аның берәр ярдәмчесе генә (алар бу вакытта штраф салынган уенчылар эскәмиясендә утырмасалар) казый белән бәхәскә керә ала.

над игрой. Его решение является окончательным. Ассистенты фиксируют проброс, положение «вне игры» и прочие игровые моменты, связанные с расположением хоккеистов и шайбы в той или иной зоне (по-английски помощников рефери так и называют: *linesmen* – буквально люди на линии).

В состав судейской бригады входят также: *двое судей, фиксирующих взятие ворот* (по одному с каждой стороны); *судья, фиксирующий счёт в игре* (с одним или двумя помощниками); *судья-хронометрист*; *судья-информатор*; *судьи на скамейке для оштрафованных игроков*, а также *судья, обеспечивающий видеозапись игры*. В спорной ситуации, связанной с взятием ворот, рефери, прежде чем принять окончательное решение, может просмотреть соответствующий фрагмент видеозаписи.

Во время матча только капитан команды или кто-то из его помощников (при условии, что они в этот момент не отбывают наказание на скамейке для оштрафованных) имеют право вступать в дискуссию с судьёй.

***Исеңдә тот!***

*Капканың алынуы* баш казый тарафыннан билгеләнә. Гол саналсын өчен, шайба ян-як беркетмәләр арасындагы капка сызыгын тулысынча кисеп үтәргә тиеш.

***Запомни!***

*Взятие ворот* засчитывается главным судьёй. Для того, чтобы гол был засчитан, шайба должна полностью пересечь линию ворот в пространстве между боковыми стойками.

Алка капкага һәр очракта да һөҗүм итүче уенчы кәшәкәсеннән кермәскә мөмкин. Әгәр ул, уенчының атуыннан соң, кайсыдыр партнёрның тимераягына тиеп капкага керсә, гол санала. Ә хоккейчы шайбага аягы белән юри типсә, гол исәпкә алынмый.

Шайба не всегда попадает в ворота непосредственно от клюшки атакующего игрока. Если после броска она случайно отскочила от конька кого-то из его партнёров в ворота, гол засчитывается. Если же хоккеист намеренно ударил по шайбе ногой, гол не засчитывается.

Әгәр алка капкага сакланучы команда уенчысына бәрелеп кергән, яки ул аны ничектер үзе керткән икән, гол санала. Шайба капкага югары күтәрелгән кәшәкә белән атылса, яки, алка кергәнче, капка урыныннан кузгалса, гол исәпкә алынмый.

Һөҗүм итүче команда уенчысы, шайба кергәнче, көндәшләр капкасы мәйданчыгында торса, гол саналмый.

Если шайба отскочила в ворота от игрока защищающейся команды, или он сам каким-либо способом завёл её в ворота, гол засчитывается. Гол не засчитывается, если шайба была направлена в ворота высоко поднятой клюшкой или если ворота оказались сдвинуты с места до того, как в них попала шайба.

Если игрок атакующей команды находится в площади ворот соперника до того, как туда попала шайба, взятие ворот не засчитывается.

## Кагыйдә бозу очраклары һәм штрафлар

Хоккейда яш күзәтелә торган кагыйдә бозу очраклары:

– *көндәшне этү* (шулай ук кәшәкә белән төртү һәм бортка этү);

– *шайбасыз уенчыга һөҗүм итү* (көч кулланып уйнау бары тик шайбаны хәзерге вакытта контрольдә тоткан уенчыга карата гына рөхсәт ителә, шул ук вакытта аңа каршы икедән дә артык адым ясарга ярамый), шулай ук *капкачыга һөҗүм итү* (хәтта капкадан ераккарак китсә дә, аңа тию кагыйдә бозу булып санала);

– *аяк чалу, көндәшне кул белән тотып туктату, эләктереп алу, арттан һөҗүм итү;*

– *көндәшкә сугу* (мәсәлән, терсәк белән);

– *югары* (җилкәдән югары) *күтәрелгән кәшәкә белән уйнау, кәшәкә белән сугу,* шулай ук *сынган яки стандартка туры килмәгән кәшәкә белән уйнау;*

– *шайбаны кул белән тоту, шайба өстенә юри егылу;*

– *тупас уйнау, сугышу;*

– *спорт нормаларына һәм дисциплинага туры килмәгән тәртип.*

Кагыйдәләр буенча түбәндәге җәзалар каралган: кече штраф, кече эскәмия штрафы, зур штраф, дисцип-

## Нарушения правил и штрафы

Наиболее распространённые нарушения в хоккее:

– *толчок соперника* (в том числе толчок клюшкой и толчок на борт);

– *атака игрока, не владеющего шайбой* (силовые приёмы в хоккее можно применять лишь против соперника, владеющего в данный момент шайбой, сделав при этом не более двух шагов ему навстречу), а также *нападение на вратаря* (считается нарушением, даже если он вышел далеко из ворот);

– *подножка, задержка соперника руками, зацеп, атака сзади*;

– *удар соперника* (например, локтем);

– *игра высоко поднятой* (т.е. поднятой выше плеча) *клюшкой, удар клюшкой*, а также *игра сломанной клюшкой или клюшкой нестандартных размеров*;

– *задержка шайбы руками, преднамеренное падение на шайбу*;

– *грубая игра, драка;*

– *неспортивное и недисциплинированное поведение.*

Правилами предусмотрены следующие наказания: малый штраф, малый скамеечный штраф, большой

*Арбитр кагыйдә бозылуын күрсәтә*



*Арбитр показывает нарушение правил*

лина нормаларына туры килмәгән тәртип өчен бирелә торган штраф, матч ахырына кадәр уеннан чыгарылу һәм штрафной (буллит) ату.

*Кече штрафка* тартылган хоккейчы чиста уен вакытының 2 минутына мәйданчыктан чыгарыла, һәм бу вакытта аны (әгәр ул травма алмаса) башка уенчы алыштыра алмый. Кагыйдәне капкачы бозган икән, ул уен мәйданыннан чыгарылмый, аның өчен партнёрларының берсенә штраф салына, һәм команда сан ягыннан азрак составта уйный. Көндәш команда гол кертсә, штрафка тартылган уенчы мәйданчыкка вакытыннан алда чыга.

штраф, штраф за недисциплинированное поведение, удаление до конца игры и штрафной бросок (буллит).

Хоккеист, наказанный *малым штрафом*, удаляется с площадки на 2 минуты чистого игрового времени и не может на это время быть заменён другим игроком (если он не получил травму). Вратарь в случае нарушения им правил с площадки не удаляется, наказание за него отбывает кто-то из полевых игроков, команда при этом играет в численном меньшинстве. Оштрафованный игрок может вернуться на площадку досрочно, если команда-соперник сумеет забить гол.

*Кече эскәмия штрафы* конкрет уенчыга түгел, ә кагыйдәне бозган өчен, командадагы уенчыларның барысына да салына (мәсәлән, сан ягыннан составны бозу). Кече штрафны «түләү» өчен, тренер капкачыдан башка теләсә нинди уенчыны сайлый ала.

*Беренче зур штрафка* тартылган уенчы (капкачыдан кала һәркем) чиста вакытның 5 минутына уеннан чыгарыла, бу вакытта аны берәү дә алыштыра алмый. *Кабатланган зур штраф* (бер уен эчендә) автомат рәвештә гаепле уенчының матч ахырына кадәр уеннан чыгарылуына китерә, һәм аның командасы 5 минут азчылыкта уйный.

*Уен ахырына кадәр уеннан чыгарылган хоккейчы* киенү бүлмәсенә кереп китә. Ул, ялгыш гамәле ярышлар үткәрү буенча җаваплы оешма тарафыннан тикшерелгәнче, команданың алдагы уеннарында катнаша алмый.

Уенчы кагыйдәне бозган вакытта, аның 2 (яки 2 дән күбрәк) партнёры штрафка тартылучылар эскәмиясендә утырса, аңа *кичектерелгән штраф* салына. Кагыйдә буенча, мәйданчыкта һәрбер командадан кимендә 3 уенчы (капкачыдан башка) булырга тиеш. Шуңа күрә бу очракта гаепле уенчы мәйданчыктан чыгарыла, аны, элегрәк штрафка тартылган партнёрларның кайсы да булса берсенең штраф вакыты беткәнче, башка уенчы алыштырып тора.

Шулай ук *һәр ике якның да кагыйдә бозу* очрагы теркәлергә мөмкин. Ул «гадәти» кагыйдә бозудан уенчы-көндәшләрнең икесенә дә штраф салынуы белән аерылып тора. Гаеплеләр, берәр команда гол керткән очракта да, штраф вакыты беткәнче, бозга чыга алмый.

*Штрафной (буллит)* түбәндәге очракларда билгеләнә:

– саклана торган команданың уенчысы, көндәшенә гол керттермәскә

*Малый скамеечный штраф* накладывается не на конкретного игрока, а на команду: за общее нарушение (например, численного состава). Для отбывания малого штрафа тренер может назначить любого игрока команды, кроме вратаря.

*Первый большой штраф* влечёт удаление провинившегося игрока (кроме вратаря) на 5 минут чистого игрового времени без права замены. *Повторный большой штраф* (в течение одной игры) автоматически приводит к удалению игрока до конца матча, его команда при этом 5 минут играет в меньшинстве.

*Хоккеист, удалённый до конца игры*, отправляется в раздевалку. Он не имеет права принимать участие в следующих играх команды, пока его проступок не будет обсуждён в организации, ответственной за проведение соревнований.

*Отложенный штраф* применяется в случае, если в момент нарушения правил игроком на скамейке штрафников уже находятся два (или более) его партнёров по команде. По правилам, на площадке должно находиться не менее 3 полевых игроков от каждой команды. В такой ситуации провинившийся игрок удаляется с площадки и заменяется другим полевым игроком до того момента, пока не истечёт штрафное время одного из его партнёров, оштрафованных ранее.

Возможно и *обоюдное нарушение*. От обычного оно отличается тем, что на обоих игроков-соперников налагается штраф. Они не имеют права выходить на площадку, пока не пройдёт время штрафа, даже если одной из команд удастся забить гол.

*Штрафной бросок (буллит)* назначается, если:

– игрок обороняющейся команды умышленно сдвинул ворота, чтобы не

теләп, махсус рәвештә капканы күчерсә (әгәр моны капкачы түгел, ә башка уенчы эшләсә, аңа да өстәмә рәвештә зур штраф салына);

– уенчы (капкачыдан кала), үз капкасы мәйданчыгында торган килеш, юри шайба өстенә ятса, аны кулына алса;

– саклanучы команда уенчысы үзенең саклану зонасында кәшәкәсен (яки аның сынган өлешен) юри шайба өстенә ташласа;

– капкачы белән бергә-бер чыккан уенчыга саклanучы команда уенчысы гол керттермәс өчен һөҗүм итсә (яки екса);

– матч бетәргә 2 (яки азрак) минут кала штрафка тартылган уенчылар эскәмиясендә кимендә ике уенчысы утырган команда сан ягыннан составын бозса.

Казый сигналы буенча буллит атучы уенчы шайбаны үзәк ноктадан көндәшләре капкасына туктамыйча алып бара һәм капкага кертергә тырыша.

дать сопернику забить гол (если это сделал полевой игрок, он также наказывается дополнительно большим штрафом);

– игрок (кроме вратаря), находясь в площади своих ворот, умышленно лёг на шайбу или взял её в руки;

– игрок обороняющейся команды умышленно бросил клюшку (или её сломанную часть) в шайбу в своей зоне защиты;

– игрок, вышедший один на один с вратарём, подвергся нападению (или был сбит) игроком защищающейся команды во избежание броска по воротам;

– за 2 (и менее) минуты до окончания матча команда, имеющая на скамейке оштрафованных не менее двух игроков, нарушила численный состав.

По сигналу судьи, игрок выполняющий буллит, не останавливаясь ведёт шайбу от центральной точки к воротам соперника и пытается поразить их.

***Исеңдә тот!***

Буллит вакытында капканы бары тик *капкачы* гына саклый. Штрафной атыла башлаганчы, ул капка мәйданчыгыннан чыгарга тиеш түгел. Буллит атучы уенчы шайбага кагылгач, голкипер капканы рөхсәт ителгән теләсә нинди юл белән саклый ала. Шайба атылганнан соң, буллит тәгәлләнгән булып санала. Уенчы капка терәкләренә, ян бортка яки капкачыга бәрелеп кире килгән шайбага кабат суга алмый.

***Запомни!***

Защищает ворота в момент выполнения буллита только *вратарь*. До начала выполнения штрафного броска он не имеет права покидать площадь ворот. После того, как игрок, выполняющий буллит, коснётся шайбы, голкипер может защищать ворота любым разрешённым способом. Когда бросок по воротам произведён, выполнение буллита считается завершённым. Игрок не имеет права добивать в ворота шайбу, отскочившую от стойки ворот, лицевого борта или вратаря.

Әгәр көндәшләр белән тигез составта уйнаучы (яки мәйданчыктан уенчылары күбрәк булган) команда хоккейчысы ниндидер юл белән шайбаны мәйданчыкның үз зонасыннан икенче команданың капка сызыгы артына җибәрсә, уен туктатыла. Шайба уенга ахыргы шайба ату ноктасында, кагыйдәне бозган команда ягында кертелә.

Уенчы шайбаны, үз зонасыннан җибәреп, көндәшенең капкасына кертсә, гол санала, һәм бу очракта проброс билгеләнми.

Әгәр, сызык янында торучы казый фикеренчә, каршы як командасы уенчысы (голкипердан кала), мөмкинлеге булып та, шайбаны, ул капка сызыгын кисеп үткәнче, тота алмаса, проброс билгеләнми, һәм уен туктатылмый.

«Уеннан тыш» халәт турындагы кагыйдә күп очракта хоккей тактикасын билгели. Бу кагыйдә буенча һөҗүм итүче хоккейчылар һөҗүм итү зонасына шайбадан алда керә алмыйлар. Зәңгәр сызыкка карата хоккейчының позициясе аның кәшәкәсе буенча түгел, ә тимераякларына карап билгеләнә. Әгәр уенчының ике тимераягы да зәңгәр сызык артында, һөҗүм итү зонасында икән, ул «уеннан тыш» санала.

*«Уеннан тыш» халәт* – хоккейда передача (пас бирү) белән бәйле бердәнбер чикләү.

## Ярышлар формуласы

Хоккей турнирлары ике схема (әйләнмә һәм уеннан төшеп калу) буенча үткәрелә.

*Әйләнмә схема* буенча барлык командалар бер-берсе белән билгеле бер санда матчлар үткәрә: җиңүче барлык уеннарда җыелган очколар санына карап билгеләнә. Хоккей бу-

Если хоккеист команды, играющей в равных составах с соперником (или в численном большинстве) тем или иным способом отправляет шайбу со своей половины поля за линию ворот другой команды, игра должна быть остановлена. Шайба вводится в игру в точке конечного вбрасывания в зоне нарушившей команды.

Если шайба, посланная игроком со своей зоны, попадает в ворота соперника, засчитывается гол, и проброс в таком случае не фиксируется.

Если, по мнению линейного судьи, игрок противоположной команды (за исключением голкипера) имеет возможность дотронуться до шайбы до того, как она пересечёт линию ворот, но намеренно не делает этого, проброс не фиксируется и игра не останавливается.

Правило о положении «вне игры» во многом определяет хоккейную тактику. Согласно этому правилу, игроки атакующей команды не могут входить в зону нападения до того, как туда попадёт шайба. Положение хоккеиста относительно синей линии определяется по его конькам, а не по клюшке. Игрок считается «вне игры», если оба его конька полностью находятся за синей линией в зоне атаки.

*«Вне игры»* – единственное ограничение, связанное с передачей (игрой в пас) в хоккее.

## Формула соревнований

Хоккейные турниры проходят по одной из двух схем: круговой или с выбыванием.

При *круговой схеме* все команды-участницы играют друг с другом определённое количество матчей: победитель определяется по общему количеству очков, набранных во всех

енча СССР беренчелегендә озак еллар дәвамында нәкъ шулай уйныйлар.

*Уеннан төшеп калу схемасын* шулай ук «кубоклы» схема яки «плей-офф» дип атыйлар. Катнашучы командалар парларга бүленә. Парларның җиңүчеләре ярышның киләсе этабына үтә, анда командалар (жирәбә яки алдан билгеләнгән ярыш схемасы буенча) яңадан парларга бүленә, һәм бу финалга – җиңүче билгеләнгәнгә кадәр шулай дәвам итә. Ярымфиналда җиңелгән командалар өченче урын өчен үзара ярыша.

играх. Именно так долгие годы играли в первенстве СССР по хоккею.

*Схему с выбыванием* называют также «кубковой» схемой или «плей-офф». Команды-участницы разбиваются на пары. Победители пар выходят в следующий этап розыгрыша, где снова делятся на пары (по жребию или в соответствии с определённой заранее схемой розыгрыша), и так вплоть до финала, в котором и определяется победитель. Команды, потерпевшие поражение в полуфиналах, разыгрывают между собой третье место.



# «Ак Барс»

- Клубның тарихы
- Зиннәтулла Билалетдинов
- «Ак Барс» командасының 2009–2010 еллар сезонындагы составы
- «Ак Барс» хоккей клубы йолдызлары
- «Ак Барс» командасының казанышлары

# «Ак Барс»

- История клуба
- Зинэтула Билялетдинов
- Текущий состав команды «Ак Барс» в сезоне 2009–2010 годов
- Звёзды хоккейного клуба «Ак Барс»
- Достижения команды «Ак Барс»

*Син «Ак Барс» командасы өчен җан атасың һәм Казан хоккейчыларының уеннарына сокланасыңмы? Ә клубның тарихын, еллар дәвамында командада эшләгән тренерларны, «барс»лар яулаган кубок-медальләрне беләсеңме соң? Юкмы? Алайса, тизрәк әлеге бүлекне укы.*

## Клубның тарихы

Команда 1956 елда Казан шәһәрендә оеша. Бу вакытта ул «Машстрой» дип атала. Чыгыш ясый башлаганда ук, атамасын «Урицкий исемендәге спорт клубы»на үзгәртеп, беренче ике сезон дәвамында Казан беренчелегендә катнаша. Ил чемпионатларында исә клуб 1958 елдан чыгыш ясый башлый.

### Исемнәре

«Урицкий исемендәге спорт клубы» (1958–1990), «Итил» (1990–1995), «Ак Барс» (1995 елдан).

### Баш тренерлары

Анатолий Муравьёв (1956–1965, 1966–1968), Исмаил Милушев (1965–1966, 1968–1971), Евгений Егоров (1971–1975), Владимир Андреев (1975–1978), Владимир Васильев (1978–1982), Олег Голямин (1982–1984), Геннадий Цыгуров (1984–1987), Виталий Стаин (1987–1988), Всеволод Елфимов (1988–1991, 1994–1995), Юрий Очнев (1991–1992), Владимир Гусев (1992), Виктор Кузнецов (1992–1994), Юрий Моисеев (1995–1999, 2001–2002), Владимир Крикунов (1999–2001), Владимир Плющев (2002–2003), Владимир Вуйтек (2003–2004), Зиннәтулла Билалетдинов (2004 елдан).

*Ты болеешь за команду «Ак Барс» и восхищаешься игрой казанских хоккеистов. А знаешь ли ты историю клуба, тренерский состав команды за все годы, кубки и медали «барсов»? Нет? Тогда поскорее читай эту главу.*

## История клуба

Команда была сформирована в 1956 году в городе Казани. В это время она называлась «Машстрой». Первые два сезона она участвовала в первенстве Казани, сменив в начале своих выступлений название на «Спортивный клуб имени Урицкого». В чемпионатах страны клуб начал выступать с 1958 года.

### Названия

«Спортивный клуб имени Урицкого» (1958–1990), «Итиль» (1990–1995), «Ак Барс» (с 1995 года).

### Главные тренеры

Анатолий Муравьёв (1956–1965, 1966–1968), Исмаил Милушев (1965–1966, 1968–1971), Евгений Егоров (1971–1975), Владимир Андреев (1975–1978), Владимир Васильев (1978–1982), Олег Голямин (1982–1984), Геннадий Цыгуров (1984–1987), Виталий Стаин (1987–1988), Всеволод Елфимов (1988–1991, 1994–1995), Юрий Очнев (1991–1992), Владимир Гусев (1992), Виктор Кузнецов (1992–1994), Юрий Моисеев (1995–1999, 2001–2002), Владимир Крикунов (1999–2001), Владимир Плющев (2002–2003), Владимир Вуйтек (2003–2004), Зинэтула Билялетдинов (с 2004 года).

## Зиннәтулла Билалетдинов

Тренер команданың уңышлы чыгыш ясавында хәлиткеч роль уйный. Ул – хоккей матчының авторы да, төп җанатары да. Хоккейчылар, аның турында сөйләгәндә: «Ул безгә уен барышының җентекле план-схемасын бер кәгазь кисәгенә ясап бирде. Безгә бары аны кабатларга гына калды», – диләр. Әйе, сүзебез хоккей даһие, шәп тренер – Зиннәтулла Хәйдәр улы Билалетдинов турында булачак.

## Зинэтула Билялетдинов

В успешном выступлении команды тренер играет определяющую роль. Он – и автор хоккейного матча, и главный болельщик команды. Хоккеисты, рассказывая о нём, говорят: «Он буквально расписал действие игры на одном листке бумаги. Нам осталось лишь повторить рисунок». Да, речь пойдёт о гении хоккея, великолепном тренере – Зинэтуле Хайдаровиче Билялетдинове.



*Зиннәтулла Билалетдинов*

*Зинэтула Билялетдинов*

Зиннәтулла Хәйдәр улы Билалетдинов 1955 елның 13 мартында Мәскәү шәһәрендә туа. Тамырлары белән ул Түбән Новгород якларыннан, Сергач районындагы татар авылы Пицәдән.

З.Билалетдинов хоккей өлкәсендә тәүге адымнарын Мәскәүнең «Динамо» командасында ясый. 1973–1988 елларда бу команданың сакчысы була.

Зинэтула Хайдарович Билялетдинов родился 13 марта 1955 года в городе Москве. Его родовые корни происходят с нижегородской земли, из татарской деревни Пица Сергачского района.

Первые шаги как хоккеист З.Билялетдинов делает в московском «Динамо». Он был защитником этого клуба в 1973–1988 годах.

Зиннәтулла Билалетдинов – алты тапкыр дөнья чемпионы (1978, 1979, 1981–1983, 1986), сигез тапкыр Европа чемпионы (1978, 1979, 1981–1983, 1985–1987), 1980 елда үткәрелгән Олимпия уеннарының көмеш призёры, 1981 елда Канада кубогы иясе, 1984 елда үткәрелгән Олимпия уеннары чемпионы, 1985 елгы дөнья чемпионатының бронза призёры, 1987 елгы дөнья чемпионатының көмеш призёры.

З.Билалетдинов СССР җыелма командасы составында 253 матчта катнаша, 21 шайба кертә. Дөнья чемпионатлары һәм кышкы Олимпия уеннары турнирларының 77 матчында уйный, 8 гол кертә. Канада кубогы турнирларының 18 матчында катнаша.

Зиннәтулла Билалетдинов илебез хоккее тарихында иң яхшы сакчыларның берсе булып танылды. Ул – СССРның атказанган спорт мастеры (1978).

Зинэтула Билялетдинов – шестикратный чемпион мира (1978, 1979, 1981–1983, 1986), восьмикратный чемпион Европы (1978, 1979, 1981–1983, 1985–1987), серебряный призёр Олимпийских игр 1980 года, обладатель Кубка Канады в 1981 году, олимпийский чемпион 1984 года, серебряный призёр чемпионата мира 1987 года, бронзовый призёр чемпионата мира 1985 года.

В составе сборной СССР Зинэтула Билялетдинов провёл 253 матча, забросил 21 шайбу. В турнирах чемпионатов мира и зимних Олимпийских игр сыграл 77 матчей, забил 8 голов. В турнирах Кубка Канады сыграл 18 матчей.

Зинэтула Билялетдинов был признан одним из лучших защитников в истории отечественного хоккея. Он – заслуженный мастер спорта СССР (1978).

## Тренерлык эшчәнлеге

Тренерлык эшчәнлеген 1988 елда Мәскәүнең «Динамо» хоккей командасында Юрий Иванович Моисеев ярдәмчеләренең берсе булып башлап җибәрә. 1988–1992 елларда ул әлеге команданың тренеры була.

З.Билалетдинов – МХЛда (Милли хоккей лигасы) эшләп алган беренче Россия тренерларының берсе. «Виннипег Джетс» (Виннипег, Канада), «Финикс Койотс» (Финикс, АКШ), «Чикаго Блэк Хоукс» (Чикаго, АКШ) командалары аның җитәкчелегендә шөгыльләнә.

1997–2000, 2002–2004 елларда З.Билалетдинов – «Динамо» хоккей командасының (Мәскәү) баш тренеры. 1999–2000 еллар сезонында аның җитәкчелегендәге «Динамо» командасы ил чемпионатының алтын медальләрен яулый. Шулай ук бу елларда

## Тренерская деятельность

Тренерскую деятельность начал в 1988 году, став одним из помощников Юрия Ивановича Моисеева в московском «Динамо». В 1988–1992 годах был тренером этой команды.

З.Билялетдинов является одним из первых российских специалистов, работавших в НХЛ (Национальной хоккейной лиге). Он тренировал «Виннипег Джетс» (Виннипег, Канада), «Финикс Койотс» (Финикс, США), «Чикаго Блэк Хоукс» (Чикаго, США).

В 1997–2000, 2002–2004 годах З. Билялетдинов – главный тренер хоккейной команды «Динамо» (Москва). В сезоне 1999–2000 годов под его руководством команда «Динамо» завоевала золотые медали чемпионата страны. Также в эти годы «Динамо» становилось серебряным призёром чемпионата России (1999), дву-

«Динамо» Россия чемпионатының көмеш призёры (1999), ике тапкыр Евролиганың көмеш призёры була (1998, 1999).

1998 һәм 2002 елларда үткәрелгән Олимпия уеннарында З.Билалетдинов Россия җыелма командасының тренерлары составына керә.

2001–2002 елларда ул – «Лугано» хоккей (Лугано, Швейцария) командасының баш тренеры.

2004 елның маеннан 2005 елның мартына кадәр Билалетдинов хоккей буенча Россия җыелма командасының баш тренеры була.

Дөнья кубогы-2004, РОСНО кубогы-2004 тә җыелма команданы җитәкли.

2004 елның 30 сентябреннән исә ул – «Ак Барс» хоккей клубының баш тренеры.

Зиннәтулла Хәйдәр улы – бик сизгер һәм сәләтле тренер, аның авыр ситуацияләрдә дә дөрес карар кабул итүе еш кына команданы җиңүгә алып килә. «Ак Барс» командасындагы һәр «бишлек»нең тигез уйнавы – З.Билалетдиновның зур тырышлыгы нәтиҗәсе.

Казанда исә «Ак Барс» бөтенләй җиңелми диярлек. Әйтерсең монда аңа тренерның төпле киңәшләре генә түгел, күпсанлы җанатарлар һәм «Татнефть Арена» үзе дә ярдәм итә.




кратным серебряным призёром Евролиги (1998, 1999).

З.Билялетдинов входил в состав тренеров сборной России на Олимпийских играх 1998 и 2002 годов.

В 2001–2002 годы он – главный тренер хоккейной команды «Лугано» (Лугано, Швейцария).

С мая 2004 года по март 2005 года Билялетдинов был главным тренером сборной России по хоккею.

Возглавлял сборную на Кубке мира-2004, Кубке РОСНО-2004.

С 30 сентября 2004 года он – главный тренер хоккейного клуба «Ак Барс».

Зинэтула Хайдарович – очень чуткий и талантливый тренер, его способность находить правильное решение в трудную минуту нередко приводит команду к победе. В том, что каждая «пятёрка» игроков в «Ак Барсе» равная, большая заслуга Билялетдинова.

В Казани же «Ак Барс» почти непобедим. Кажется, здесь ему помогают не только основательные советы тренера, но и многочисленные болельщики, и даже сама «Татнефть Арена».




*КХЛ чемпионнары (2008–2009)*




*Чемпионы КХЛ (2008–2009)*




*Чемпионнар (2009–2010)*




*Чемпионы (2009–2010)*




*Татнефть Арена*

***Син беләсеңме?***

*«Татнефть Арена»* – спорт һәм концерт комплексы. Шәһәребезнең Чистай урамындагы әлеге бина Казансу елгасы ярына урнашкан.
2005 елның 26 декабреннән «Ак Барс» хоккей командасының Казандагы матчлары монда үтә.
«Татнефть Арена» бинасы 8874 тамашачыны сыйдыра.
Ул 28 000 кв. метр мәйданны били.

***Знаешь ли ты?***

*«Татнефть Арена»* – это спортивно-концертный комплекс, находится на улице Чистопольской города Казани, на берегу реки Казанки.
С 26 декабря 2005 года хоккейная команда «Ак Барс» проводит здесь свои домашние матчи.
Вместимость «Татнефть Арены» – 8874 зрителя.
Она занимает площадь в 28 000 кв. метров.






*Матч алдыннан*

*Перед матчем*

## «Ак Барс» командасының 2009–2010 еллар сезонындагы составы

| Капкачылар | | | |
|---|---|---|---|
| № | Уенчы | «Ак Барс»ка килгән елы | Туган урыны |
| 1 | Сергей Николаев | 2008 | Саратов, Россия |
| 20 | Станислав Галимов | 2007 | Чиләбе, Россия |
| 35 | Петри Веханен | 2009 | Раума, Финляндия |

| Сакчылар | | | |
|---|---|---|---|
| № | Уенчы | «Ак Барс»ка килгән елы | Туган урыны |
| 2 | Степан Захарчук | 2009 | Самара, Россия |
| 5 | Илья Никулин (А) | 2005 | Мәскәү, Россия |
| 8 | Андрей Мухачёв | 2008 | Екатеринбург, Россия |
| 9 | Андрей Первышин | 2004 | Архангельск, Россия |
| 14 | Игорь Щадилов | 2009 | Мәскәү, Россия |
| 59 | Вячеслав Буравчиков | 2006 | Мәскәү, Россия |
| 74 | Алексей Емелин | 2007 | Тольятти, Россия |
| 75 | Григорий Панин | 2007 | Тольятти, Россия |
| 82 | Евгений Медведев | 2007 | Чиләбе, Россия |



## Текущий состав команды «Ак Барс» в сезоне 2009–2010 годов

| Голкиперы | | | |
|---|---|---|---|
| № | Игрок | Год прихода в «Ак Барс» | Место рождения |
| 1 | Сергей Николаев | 2008 | Саратов, Россия |
| 20 | Станислав Галимов | 2007 | Челябинск, Россия |
| 35 | Петри Веханен | 2009 | Раума, Финляндия |

| Защитники | | | |
|---|---|---|---|
| № | Игрок | Год прихода в «Ак Барс» | Место рождения |
| 2 | Степан Захарчук | 2009 | Самара, Россия |
| 5 | Илья Никулин (А) | 2005 | Москва, Россия |
| 8 | Андрей Мухачёв | 2008 | Екатеринбург, Россия |
| 9 | Андрей Первышин | 2004 | Архангельск, Россия |
| 14 | Игорь Щадилов | 2009 | Москва, Россия |
| 59 | Вячеслав Буравчиков | 2006 | Москва, Россия |
| 74 | Алексей Емелин | 2007 | Тольятти, Россия |
| 75 | Григорий Панин | 2007 | Тольятти, Россия |
| 82 | Евгений Медведев | 2007 | Челябинск, Россия |



| Һөҗүмчеләр | | | | |
|---|---|---|---|---|
| № | Уенчы | Позициясе | «Ак Барс»ка килгән елы | Туган урыны |
| 10 | Янне Песонен | СҺ[1] | 2009 | Суомуссалми, Финляндия |
| 11 | Евгений Бодров | ҮҺ[2] | 2009 | Тольятти, Россия |
| 13 | Ханнес Хювенен | УҺ[3] | 2009 | Оулу, Финляндия |
| 17 | Роман Кукумберг | СҺ | 2009 | Братислава, Словакия |
| 19 | Михаил Юньков | ҮҺ | 2009 | Воскресенск, Россия |
| 25 | Данис Зарипов (А) | СҺ | 2001 | Чиләбе, Россия |
| 26 | Яркко Иммонен | ҮҺ | 2009 | Рантасалми, Финляндия |
| 27 | Алексей Терещенко | ҮҺ | 2009 | Можайск, Россия |
| 30 | Александр Степанов (А) | УҺ | 2005 | Мәскәү, Россия |
| 34 | Дмитрий Обухов | УҺ | 2005 | Казан, Россия |
| 39 | Нико Капанен | ҮҺ | 2008 | Хаттула, Финляндия |
| 57 | Алексей Бадюков | ҮҺ | 2008 | Мәскәү, Россия |
| 67 | Дмитрий Казионов | ҮҺ | 2006 | Мәскәү, Россия |
| 81 | Никита Алексеев | СҺ | 2007 | Мурманск, Россия |
| 86 | Николай Лемтюгов | УҺ | 2009 | Чиләбе, Россия |
| 95 | Алексей Морозов (К) | УҺ | 2004 | Мәскәү, Россия |

[1] СҺ – сул як һөҗүмче.
[2] ҮҺ – үзәк һөҗүмче.
[3] УҺ – уң як һөҗүмче.

| Нападающие | | | | |
|---|---|---|---|---|
| № | Игрок | Позиция | Год прихода в «Ак Барс» | Место рождения |
| 10 | Янне Песонен | ЛН[1] | 2009 | Суомуссалми, Финляндия |
| 11 | Евгений Бодров | ЦН[2] | 2009 | Тольятти, Россия |
| 13 | Ханнес Хювенен | ПН[3] | 2009 | Оулу, Финляндия |
| 17 | Роман Кукумберг | ЛН | 2009 | Братислава, Словакия |
| 19 | Михаил Юньков | ЦН | 2009 | Воскресенск, Россия |
| 25 | Данис Зарипов (А) | ЛН | 2001 | Челябинск, Россия |
| 26 | Яркко Иммонен | ЦН | 2009 | Рантасалми, Финляндия |
| 27 | Алексей Терещенко | ЦН | 2009 | Можайск, Россия |
| 30 | Александр Степанов (А) | ПН | 2005 | Москва, Россия |
| 34 | Дмитрий Обухов | ПН | 2005 | Казань, Россия |
| 39 | Нико Капанен | ЦН | 2008 | Хаттула, Финляндия |
| 57 | Алексей Бадюков | ЦН | 2008 | Москва, Россия |
| 67 | Дмитрий Казионов | ЦН | 2006 | Москва, Россия |
| 81 | Никита Алексеев | ЛН | 2007 | Мурманск, Россия |
| 86 | Николай Лемтюгов | ПН | 2009 | Челябинск, Россия |
| 95 | Алексей Морозов (К) | ПН | 2004 | Москва, Россия |

[1] ЛН – левый нападающий.
[2] ЦН – центральный нападающий.
[3] ПН – правый нападающий.

## «Ак Барс» хоккей клубы йолдызлары

## Звезды хоккейного клуба «Ак Барс»



### АЛЕКСЕЙ МОРОЗОВ

**Туган көне һәм урыны:** 1977 елның 16 феврале, Мәскәү шәһәре
**Буе:** 185 см
**Авырлыгы:** 93 кг

Алексей Морозов хоккей өлкәсендә тәүге адымнарын Мәскәүнең «Крылья Советов» командасында ясый. Бу команда өчен беренче матчларын ул 1993–1994 еллар сезонында уздыра. Киләсе Россия чемпионатында исә яшь форвард, 48 матчта 15 шайба кертеп, үзүзен таныта. Тагын берничә елын Россиядә уздырганнан соң, Морозов 1997 елда Төньяк Америкага күчеп китә.

Беренче сезонда ук ул, «Питтсбург Пингвинз» (Питтсбург) өчен 26 очко (13+13)[1] җыеп, МХЛның (Милли хоккей лигасының) яңа уенчылары символик җыелма командасына керә. Шунысы кызык: Алексей МХЛдагы карьерасын легендар хоккейчы Марио Лемье кебек башлап җибәрә. Беренче шайбасын беренче матчның беренче сменасында беренче сугуы белән үк кертә.

«Питтсбург» командасында үткәрелгән җиде сезон эчендә һөҗүмче 451 матчта уйный, 84 шайба кертә һәм 219 очко җыя. Төньяк Америкада Морозовка, «Нью-Джерси» командасы белән матчларда уңышлы уйнаганы өчен, «The Devil Killer» («иблисне үтерүче», «иблистәй үтерүче») дигән кушамат тагалар.

[1] (13+13) – 13 гол һәм 13 пас.

### АЛЕКСЕЙ МОРОЗОВ

**Дата и место рождения:** 16 февраля 1977 года, город Москва
**Рост:** 185 см
**Вес:** 93 кг

Алексей Морозов – воспитанник команды «Крылья Советов». Первые матчи за эту команду он провёл в сезоне 1993–1994 годов. Уже в следующем чемпионате России юный форвард заявил о себе, забросив 15 шайб в 48 матчах. Проведя ещё несколько лет в России, в 1997 году Морозов переехал в Северную Америку.

В дебютном сезоне он набрал 26 очков (13+13)[1] за «Питтсбург Пингвинз» (Питтсбург) и вошёл в символическую сборную новичков НХЛ (Национальной хоккейной лиги). Любопытно, что Алексей дебютировал в НХЛ так же, как и легендарный хоккеист Марио Лемье: забросил первую шайбу первым же броском в первой смене в первом матче.

За семь сезонов в «Питтсбурге» нападающий сыграл 451 матч, забросил 84 шайбы и набрал 219 очков. В Северной Америке Морозов получил прозвище «The Devil Killer» («убийца дьявола», «дьявольский убийца») за успешную игру в матчах с «Нью-Джерси».

[1] (13+13) – 13 голов и 13 пасов.

МХЛда (Милли хоккей лигасы) локаут булганда, хоккеист «Ак Барс» командасы өчен чыгыш ясый башлый, бу вакытта командага МХЛдан күп кенә йолдызлар килә. Составлары көчле булуга карамастан, казанлылар чемпион була алмый. Морозов «Ак Барс»та калырга карар кыла, һәм 2005–2006 еллар сезонында инде команда алтын медальләр яулый. Даими чемпионатта Морозов иң күп (23) шайба кертүче була. Алексей плей-оффта иң яхшы уенчы булып таныла. Аның исәбендә 13 уенда 26 очко (13+13). 2005–2006 еллар сезоны тәмамланганнан соң, ул Казан клубы белән янә өч елга контракт төзи.

2007 елның гыйнварында «Ак Барс» командасы Европа чемпионнары кубогын яулый, Морозов турнирның иң яхшы форварды һәм алыштыргысыз уенчысы дип табыла. 2006–2007 еллар сезонында һөҗүмче, 83 очко (34+49) җыеп, Россия суперлигасында рекорд куя.

2006 елгы дөнья чемпионатында Алексей, 7 матчта 8 шайба кертеп, турнирның иң яхшы снайперы булып таныла.

Россия чемпионатының 2007–2008 еллар сезонында ул 30 шайба кертә һәм 33 гол передачасы ясый, ләкин «Ак Барс» бу юлы бары ярымфиналга гына барып җитә.

2009 елда финалның җиденче матчында Морозов чын капитаннарча бердәнбер, ләкин хәлиткеч шайба кертә, һәм Казан «Ак Барс»ы Россия хоккее тарихында беренчеләрдән булып Гагарин кубогын яулый.

2009 елгы дөнья чемпионатында Алексей шулай ук җыелма командаларның капитаны була һәм команданы алтын медальләргә алып килә.

Алексей Морозов – Олимпия уеннарының көмеш призёры (1998), Россия чемпионы (2005–2006), Россия чемпионатының көмеш призёры

Во время локаута в НХЛ (Национальной хоккейной лиги) хоккеист стал выступать за «Ак Барс», в который в 2004 году приехало много звёзд из НХЛ. Несмотря на сильный состав, казанцам не удалось стать чемпионами. Морозов принял решение остаться в «Ак Барсе», и в сезоне 2005–2006 годов команда выиграла золото. В регулярном чемпионате Морозов забросил больше всех шайб (23). Алексей был признан лучшим игроком плей-офф. На его счету 26 очков (13+13) в 13 играх. По окончанию сезона 2005–2006 годов он снова подписал контракт с казанским клубом ещё на три года.

В январе 2007 года команда «Ак Барс» выиграла Кубок европейских чемпионов, Морозов был назван лучшим форвардом и самым ценным игроком турнира. В сезоне 2006–2007 годов нападающий установил рекорд российской суперлиги, набрав 83 очка (34+49).

На чемпионате мира в 2006 году Алексей забил 8 шайб в 7 матчах и стал лучшим снайпером турнира.

В сезоне 2007–2008 годов чемпионата России он забросил 30 шайб и сделал 33 голевые передачи, но «Ак Барс» на этот раз дошёл лишь до полуфинала.


В 2009 году в седьмом матче финальной серии Морозов, как и полагается капитану, забил единственную, но решающую шайбу, и казанский «Ак Барс» впервые в истории российского хоккея завоевал Кубок Гагарина.

На чемпионате мира-2009 Алексей также был капитаном сборной и привёл команду к золотым медалям.

Алексей Морозов – серебряный призёр Олимпийских игр (1998), чемпион России (2005–2006), серебряный призёр чемпионата России (2006–2007), бронзовый призёр чемпионата

(2006–2007), дөнья чемпионатының бронза призёры (2007), дөнья чемпионы (2008, 2009), Гагарин кубогы иясе һәм КХЛ чемпионы (2009, 2010).

мира (2007), чемпион мира (2008, 2009), обладатель Кубка Гагарина и чемпион КХЛ (2009, 2010).




*«Ак Барс» – чемпион!*

## ДАНИС ЗАРИПОВ

**Туган көне һәм урыны:**
1981 елның 26 марты,
Чиләбе шәһәре
**Буе:** 183 см
**Авырлыгы:** 81 кг



## ДАНИС ЗАРИПОВ

**Дата и место рождения:**
26 марта 1981 года,
город Челябинск
**Рост:** 183 см
**Вес:** 81 кг

Данис Зарипов хоккей өлкәсендәге эшчәнлеген Россия чемпионатының югары лигасында чыгыш ясаган Чиләбе «Мечел»ында башлап җибәрә. 1998 елда 17 яшьлек форвард үзен Төньяк Америкада сынап карарга уйлый. 1998–1999 еллар сезонында ул Көнбатыш хоккей лигасында (WHL) «Свифт Каррент Бронкос» (Канада) командасы өчен чыгыш ясый һәм 62 матчта 23 шайба кертә, шулай ук 8 передача ясый.

2001–2002 еллар сезонында Зарипов «Ак Барс» командасында уйный башлый.

Зарипов Россия җыелма командасына кандидат буларак 2003 елда ук карала башласа да, милли команда составында дөнья чемпионатына бары 2006 елда гына бара. Ул ел һөҗүмче өчен гомумән уңышлы була: даими беренчелектә ул 49 очко җыя, плей-оффта 3 гол кертә, 8 передача ясый һәм шул рәвешле «Ак Барс» командасының Россия чемпионы булуына зур өлеш кертә. 2006 елгы дөнья чемпионатында Данис 2 шайба кертә һәм 3 передача ясый, ләкин бу турнирда Россия җыелма командасы бары чирек финалга гына барып җитә.

2006–2007 еллар сезонында форвард, 53 матчта 62 очко (32+30) җыеп, үз рекордын куя. Моңа шулай ук Алексей Морозов һәм Сергей Зиновь-

Данис Зарипов начал карьеру в челябинском «Мечеле», выступавшем в высшей лиге чемпионата России. В 1998 году 17-летний форвард решил попробовать свои силы в Северной Америке. Челябинец выступал за «Свифт Каррент Бронкос» (Канада) в Западной хоккейной лиге (WHL) в сезоне 1998–1999 годов и в 62 матчах забросил 23 шайбы, а также сделал 8 передач.

В сезоне 2001–2002 годов Зарипов начал играть в команде «Ак Барс».

С 2003 года Зарипов стал рассматриваться как кандидат в сборную России, но на чемпионат мира в составе национальной команды поехал лишь в 2006 году. Тот год вообще получился очень удачным для нападающего: в регулярном первенстве он набрал 49 очков, в плей-офф забил 3 гола и сделал 8 передач, и помог своему клубу стать чемпионом России. На чемпионате мира 2006 года Данис забросил 2 шайбы и сделал 3 передачи, но на этом турнире сборной России удалось дойти лишь до четвертьфинала.

В сезоне 2006–2007 годов форвард установил личный рекорд, набрав 62 очка (32+30) в 53 матчах. Помогла этому и игра в одном звене с Алексеем Морозовым и Сергеем Зиновьевым. После того, как «Ак Барс» выиграл

ев белән бергә уйнау да ярдәм итә. «Ак Барс» көмеш медальләр яулаганнан соң, Данисны Россия җыелма командасына чакыралар. 2007 елда Мәскәүдә үткәрелгән дөнья чемпионатында ул «плюс-минус» күрсәткече буенча иң яхшы уенчыларның берсе дип танылa.

2008 елда Канадада үткәрелгән дөнья чемпионатында Зарипов Россия җыелма командасы составында турнирның җиңүчесе була. Бер елдан соң ул, 2 матчта гына катнашуына карамастан (травма алу сәбәпле, команда составыннан төшеп кала), 3 очко (2+1) җыярга өлгерә.

Данис Зарипов – Россия чемпионы (2005–2006), Россия чемпионатының көмеш призёры (2006–2007), дөнья чемпионатының бронза призёры (2007), дөнья чемпионы (2008, 2009), Гагарин кубогы иясе һәм КХЛ чемпионы (2009, 2010).

серебро, Данис получил приглашение в сборную России. На чемпионате мира в 2007 году в Москве он был признан одним из лучших в команде по показателю «плюс-минус».

На чемпионате мира в Канаде в 2008 году Зарипов в составе сборной России стал победителем турнира. Год спустя Зарипов сыграл всего два матча (выбыв из состава из-за травмы), но успел набрать 3 очка (2+1).

Данис Зарипов – чемпион России (2005–2006), серебряный призёр чемпионата России (2006–2007), бронзовый призёр чемпионата мира (2007), чемпион мира (2008, 2009), обладатель Кубка Гагарина и чемпион КХЛ (2009, 2010).

## «Ак Барс» командасының казанышлары

– Ике тапкыр РСФСР чемпионы (1962, 1976).

– Дүрт тапкыр Россия чемпионы (1997–1998, 2005–2006, 2008–2009, 2009–2010).

– Россия чемпионатларының өч тапкыр көмеш призёры (1999–2000, 2001–2002, 2006–2007).

– Континенталь кубок ярышларының бронза призёры (1999).

– Россия чемпионатларының өч тапкыр бронза призёры (2003–2004).

– Европа чемпионнары кубогы иясе (2007).

– Континенталь кубок иясе (2008).

– Гагарин кубогы иясе һәм КХЛ чемпионы (2009, 2010).

## Достижения команды «Ак Барс»

– Двукратный чемпион РСФСР (1962, 1976).

– Четырёхкратный чемпион России (1997–1998, 2005–2006, 2008–2009, 2009–2010).

– Трёхкратный серебряный призёр чемпионатов России (1999–2000, 2001–2002, 2006–2007).

– Бронзовый призёр розыгрыша Континентального кубка (1999).

– Бронзовый призёр чемпионата России (2003–2004).

– Обладатель Кубка европейских чемпионов (2007).

– Обладатель Континентального кубка (2008).

– Обладатель Кубка Гагарина КХЛ (2009, 2010).

# «Ак Бүре»

- Клубның тарихы
- Балалар тренеры
- Көндәлек тренировкалар
- «Ак Бүре» командасының 2009—2010 еллар сезонындагы составы
- Чын хоккейчы нинди булырга тиеш?

# «Ак Буре»

- История клуба
- Детский тренер
- Ежедневные тренировки
- Текущий состав команды «Ак Буре» в сезоне 2009–2010 годов
- Каким должен быть настоящий хоккеист?

*Хәзер син хоккей тарихы, аның кагыйдәләре, «Ак Барс» командасы турында да беләсең. Инде тимераякларыңны киеп, тренировкага йөгерергә вакыт. Ә менә яшь хоккейчылар кайда тәрбияләнә соң? Аларның тренеры кем? Көн тәртипләре нинди? Сорауларыңа җавапны син әлеге бүлектән табарсың.*

Казан шәһәрендәге спорт мәктәпләренең саны берничә дистәгә җитә. Без исә шуларның берсе – «Ак Бүре» балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе (БЯСМ) турында сөйләрбез.

## Клубның тарихы

Әлеге спорт мәктәбе 2000 елда оешаһәм Совет районының балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе дип атала. 2006 елда исә ул «Ак Бүре» исемен ала. Монда балалар теннис, ирекле көрәш, дзюдо, каратэ, фигуралы шуу һәм хоккей белән шөгыльләнә.

Ак Бүре элек-электән ерак бабаларыбыз – төркиләрнең тотемы булып саналган. Кешеләр аның гадәттән тыш көчкә ия булуына, авыр чакта ярдәмгә килүенә ышанганнар. Ак бүре исемен йөрткән бу мәктәп тә – балаларның чын дусты. Чөнки монда балаларның хыяллары чынга аша.

«Ак Бүре» боз аренасы 2005 елның августында Казанга мең ел тулу уңаеннан ачыла. Октябрь аенда исә 1996–1999 елларда туган балалар арасыннан шайбалы хоккей буенча дүрт укыту-күнекмә бирү төркемнәре төзелә. Даими шөгыльләнүләрнең нәтиҗәсе озак көттерми: 2005–2006 еллар сезонында «Ак Бүре» яшүсмерләр командасы «Алтын шайба» бүләгенә үткәрелгән ярышларда беренче урынны ала.

Бүгенге көндә «Ак Бүре»дә 8 яшьтән алып 14 яшькәчә малайлар шөгыльләнә. Алар яшь буенча 7 төркемгә бүленә.

*Теперь ты знаешь и историю хоккея, и его правила, и о команде «Ак Барс». Самое время надеть коньки и бежать на тренировку. Но где же занимаются юные хоккеисты? Кто их тренирует? Какой у них распорядок дня? Ответы на свои вопросы ты найдешь в этой главе.*

В Казани несколько десятков спортивных школ. Мы же расскажем о Детско-юношеской спортивной школе (ДЮСШ) «Ак Буре».

## История клуба

Эта спортивная школа была сформирована в 2000 году и называлась детско-юношеской спортивной школой Советского района. А в 2006 году она получила название «Ак Буре». Здесь ребята занимаются теннисом, вольной борьбой, дзюдо, каратэ, фигурным катанием и хоккеем.

Ак буре, то есть белый волк, издревле считался тотемом предков татар – тюрков. Люди верили, что он обладает сверхъестественной силой и приходит на помощь в трудную минуту. Школа, которая носит название белого волка – настоящий друг ребят. Ведь здесь, действительно, сбываются детские мечты.

Ледовая арена «Ак Буре» открылась в августе 2005 года в преддверии тысячелетия Казани. В октябре уже были укомплектованы четыре учебно-тренировочные группы по хоккею с шайбой ребятами 1996–1999 года рождения. Результат не замедлил сказаться: в сезоне 2005–2006 годов команда юношей «Ак Буре» заняла первое место в соревнованиях на приз «Золотая шайба».

Сейчас в «Ак Буре» тренируются ребята от 8 до 14 лет. Они разделены на 7 возрастных групп.




*«Ак Бүре» боз аренасы*

*Ледовая арена «Ак Буре»*

## Балалар тренеры

### АЛМАЗ ЯКУПОВ

**Туган көне һәм урыны:**
1982 елның 3 феврале,
Казан шәһәре



1996 елда туган балалар төркеме Якупов Алмаз Илшат улы җитәкчелегендә шөгыльләнә.

Хоккей белән биш яшендә үк үзеннән зуррак малайлар командасында шөгыльләнә башлый. 1989 елда яшьтәшләреннән аерым төркем оешкач, Алмаз Урицкий исемендәге спорт клубының элекке бомбардиры Геннадий Семёнович Маслов җитәкчелегендәге шул командага күчә.

Соңрак, спорт мәктәбен бетергәнче, малайларның тренеры Рөстәм Наил улы Габделхәев була.

Алмаз Якупов сигез яшенә кадәр сакчы позициясендә икенче звенода уйный, ә аннары капка саклауга күчә. Бүген ул капкачы булу тарихын елмаеп искә ала...

Казан малайлары зур исәп (14:2) белән Новочебоксарскиның «Сокол» командасына оттыргач, тренер Алмазга капкачы булырга тәкъдим итә. Якупов теләми: һәр малай кебек, аның да капка саклыйсы түгел, ә гол кертәсе килә. Тик тренерның карарын кечкенә хоккеистның күз яшьләре дә, әтисенең мәктәпкә килүе дә үзгәртә алмый. Һәм икенче уенда инде Ал-

## Детский тренер

### АЛМАЗ ЯКУПОВ

**Дата и место рождения:**
3 февраля 1982 года,
город Казань

Возрастную группу 1996 года рождения тренирует Якупов Алмаз Ильшатович.

Начал заниматься хоккеем с пяти лет в команде, где играли ребята постарше. В 1989 году состоялся набор его возрастной группы, и Алмаз перешёл в команду под руководством Геннадия Семёновича Маслова, в прошлом бомбардира спортивного клуба имени Урицкого.

Затем ребят начал тренировать Рустем Наилевич Абдулхаев, который был с ними до завершения школы.

Алмаз Якупов до восьми лет играл на позиции защитника и весьма успешно выступал во втором звене, а потом начал защищать ворота. Теперь он, улыбаясь, вспоминает эту историю...

После того, как казанские мальчишки с крупным счётом (14:2) проиграли команде «Сокол» из Новочебоксарска, тренер предложил Алмазу стать вратарём. Якупов не хотел этого: как любой мальчишка, он мечтал забивать, а не защищать ворота. Но решение тренера не смогли изменить ни слёзы маленького хоккеиста, ни отец мальчика, пришедший в школу.

маз капкада була. Иң кызыгы: аңа капкачы булу ошый, һәм тагын берничә уеннан соң инде ул башка бернинди амплуада да уйнарга теләми.

И на следующей игре Алмаз уже стоял на воротах. Самое интересное – ему понравилось быть вратарём и через несколько игр он уже не хотел играть ни в каком другом амплуа.



*Алмаз Якупов бала чагында*

*Алмаз Якупов в детстве*

Алмаз унбер яшеннән махсус спорт классына йөри башлый. Монда хоккей дәресләренә зур игътибар бирелә.

Унынчы сыйныфтан соң Алмаз Якуповны «Ак Барс-2» командасына чакыралар (анда ул Урицкий исемендәге спорт клубының элекке капкачысы, «Ак Барс» хоккей клубы капкачыларының бүгенге тренеры Сергей Михайлович Абрамов җитәкчелегендә шөгыльләнә). Бу аның тормышында бик әһәмиятле вакыйга була, чөнки спорт мәктәбеннән соң спортчы йә яшьләр командасында уйный башлый, йә аның хоккей эшчәнлеге бөтенләй туктала.

2002 елда яшь капкачыны Казанның «Ак Барс» командасына чакыралар. Монда ул Юрий Моисеев һәм Владимир Вуйтек җитәкчелегендә уйный.

С одиннадцати лет Алмаз начал ходить в специальный спортивный класс. Здесь уделялось большое внимание занятиям хоккеем.

После десятого класса Алмаза Якупова пригласили в «Ак Барс-2» (там он тренировался под руководством Сергея Михайловича Абрамова – бывшего вратаря спортивного клуба имени Урицкого, нынешнего тренера вратарей хоккейного клуба «Ак Барс»). Это было значительным событием в его жизни, ведь после спортивной школы спортсмен или начинает выступать за молодёжную команду, или ему приходится завершить карьеру хоккеиста.

В 2002 году молодого вратаря приглашают в казанский «Ак Барс». Здесь он играл под руководством Юрия Моисеева и Владимира Вуйтека.




*Дмитрий Ячанов, Сергей Абрамов, Алмаз Якупов, Андрей Царёв*

2003 елда Алмаз Кама физик культура институтын (Яр Чаллы) тәмамлый.

2003–2004 елларда Барнаул шәһәрендәге «Мотор» командасының капка сакчысы була.

2005 елда «Ак Барс» спорт мәктәбендә шөгыльләнүче капкачыларның һәм «Ак Барс-2» командасы голкиперларының тренеры булып эшли башлый.

2009 елда ул Лесгафт исемендәге академиянең Тренерлар югары мәктәбен (Санкт-Петербург) тәмамлый.

2009 елдан Алмаз Якупов – «Ак Бүре» командасы тренеры.

Алмаз Якупов үзенең әти-әнисе Илшат Илгизәр улы һәм Розалия Габделхәй кызына бик рәхмәтле. Аңа үз юлын табарга ярдәм итүчеләр дә, беренче күз яшьләрен сөртүчеләр дә, беренче уңышларына чын күңелдән сөенүчеләр дә нәкъ менә алар булган бит!

Алмаз Якупов команда уңышының төп компонентлары дип тренер һәм уенчы мөнәсәбәтен, теләк һәм тырыш-

В 2003 году Алмаз окончил Камский институт физической культуры (Набережные Челны).

В 2003–2004 годах был стражей ворот «Мотора» из города Барнаула.

В 2005 году начал работать в школе «Ак Барс» тренером по вратарям и тренировать голкиперов «Ак Барса-2».

В 2009 году он окончил Высшую школу тренеров академии имени Лесгафта (Санкт-Петербург).

С 2009 года Алмаз Якупов – тренер команды «Ак Буре».

Алмаз Якупов очень благодарен своим родителям Ильшату Ильгизаровичу и Рузалие Абдулхаевне. Ведь именно они помогли ему выбрать свой путь, вытирали его первые слёзы и искренне радовались его самым первым успехам.

Главными составляющими успеха команды Алмаз Якупов считает взаимоотношение тренера и игрока, желание и усердие. «Если хочешь стать

лыкны саный. «Яхшы хоккейчы дәрәҗәсенә ирешергә телисең икән, үз эшеңнең фанаты бул, – ди ул. – Көндәлек күнекмәләр – уңышның яртысы гына. Шуңа күрә тренер кушуы буенча гына түгел, үз өстеңдә мөстәкыйль рәвештә дә шөгыльләнергә өйрән».

## Көндәлек тренировкалар

Алмаз Илшат улы җитәкчелек иткән төркемдә 26 малай шөгыльләнә. Алар гадәти мәктәптәге укуларын «Ак Буре»дәге көндәлек тренировкалар белән бергә алып баралар.

Сәгать ярымлык өйрәнүләр көнгә бер тапкыр үткәрелә. Һәр тренировкада хоккейчы өчен кирәкле сыйфат-күнекмәләрне үстерә торган күнегүләр ясала.

Дүшәмбе – техникага (шуу техникасы, кәшәкә белән уйнау техникасы), сишәмбе – тизлеккә, чәршәмбе тизлек һәм көчне үстерүче күнегүләргә игътибар бирсәләр, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә техника, тактик әзерлеккә басым ясала.

*«Ак Буре» командасы тренировка вакытында*

хорошим хоккеистом, будь фанатом своего дела, – говорит он. – Ведь ежедневные тренировки – это только полдела. Научись работать над собой не только под присмотром тренера, но и самостоятельно».

## Ежедневные тренировки

Под руководством Алмаза Ильшатовича тренируются 26 ребят. Они сочетают успешную учёбу в обычной общеобразовательной школе с ежедневными тренировками в «Ак Буре».

Тренировки проводятся по полтора часа один раз в день. На каждой тренировке выполняются упражнения, развивающие различные качества, навыки, необходимые для хоккеистов.

Если в понедельник уделяется внимание упражнениям для развития техники (техники катания, техники владения клюшкой), во вторник – быстроте, в среду – скорости и силе, то в четверг и в пятницу проводятся занятия, направленные на усовершенствование техники и тактической подготовки.



*Команда «Ак Буре» во время тренировки*



*Уеннан бер күренеш* *Момент из игры*

Шимбә һәм якшәмбе көннәрендә уеннар уздырыла. Бер атнада «Ак Бүре» башка шәһәрләрдән килгән командаларны Казанда, үз бозында кабул итсә, икенче атнада көндәшләренә «кунакка бара».

В субботу и воскресенье проводятся игры. На одной неделе «Ак Буре» принимает команды из других городов в Казани, на своём льду, на другой – едет в гости к своим соперникам.



## «Ак Буре» командасының 2009-2010 еллар сезонындагы составы


## Состав команды «Ак Буре» в сезоне 2009-2010 годов

### Капкачылар — Голкиперы



№ 1

Золотухин Олег



№ 20

Камалиев Рөстәм


Камалеев Рустем



№ 21


Надёжин Михаил

### Сакчылар — Защитники



№ 2


Ишалин Айрат



№ 4

Гыйззәтуллин Азат

Гиззатуллин Азат




№ 5

Овчинников Алексей



№ 13

Храменков Михаил



№ 15

Гатауллин Артур



№ 19
Ганиев Гадел
Ганеев Адель



№ 21

Шершнёв Леонид



№ 23

Ледянкин Максим

## Һөҗүмчеләр                Нападающие



№ 8
Фәттахов Булат
Фатахов Булат



№ 9

Козлов Павел



№ 10
Әхмәтханов Гадел
Ахметханов Адель




№ 11

Афанасьев Максим



№ 12

Платонов Данил



№ 13


Мартемьянов Семён



№ 13(2)
Вәлиуллин Тимур
Валиуллин Тимур



№ 14
Сафин Илдар
Сафин Ильдар



№ 16

Сафин Булат




№ 17

Емельянов Данила



№ 18
Җамалетдинов Линар
Замалутдинов Линар




№ 24

Орлов Арсений



№ 25

Антонов Михаил



№ 42

Паняев Дмитрий



№ 55

Феоктистов Ярослав




*Уеннан соң* — *После игры*

## Чын хоккейчы нинди булырга тиеш?

Малайлар хоккейчы өчен кирәкле төп сыйфатлар дип салкын канлылыкны, азарт, тизлек, спорт усаллыгын, түземлелекне саныйлар. Иң мөһиме – командадагы дуслыкның кадерен белү һәм бер-береңне аңлау. «Тик шәп хоккейчыга да иң беренче чиратта яхшы тренер кирәк», – дип уйлыйлар алар. Ул тәҗрибәле дә, ярдәмчел дә, таләпчән дә, гадел дә һәм үз укучыларына үрнәк тә булырга тиеш. Шул очракта гына син хоккей серләренә төшенә һәм чын чемпион була аласың.

*Кем белә, бу малайларны киләчәктә нәрсә көтә? Мөгаен, аларның берсе хоккей йолдызы, икенчесе менә дигән тренер булыр, ә өченчесе, елмаеп, кечкенә улына үзенең иске тимераякларын күрсәтер дә әлеге мавыктыргыч спорт төре турында сөйләр. Болар барысы да алда... Ә бүген алар – нәкъ синең кебек, чын чемпион булырга хыялланучы гап-гади малайлар...*

## Каким должен быть настоящий хоккеист?

Важными качествами для хоккеиста ребята считают хладнокровие, азарт, скорость, спортивную злость, выносливость. Главное – ценить дружбу в команде, достигать взаимопонимания. «Но даже классному игроку прежде всего нужен хороший тренер», – думают они. Он должен быть опытным, отзывчивым, требовательным, справедливым и давать пример своим ученикам. Ведь только в этом случае ты сможешь познать секреты хоккея и стать настоящим чемпионом.

*Кто знает, что будет с этими мальчишками в будущем? Наверное, один из них станет звездой хоккея, другой – отличным тренером, а третий с улыбкой покажет совсем ещё маленькому сынишке свои старые коньки и расскажет ему об этом прекрасном виде спорта. Но это будет потом... А сегодня они – обычные ребята, которые так же, как и ты, мечтают стать настоящими чемпионами...*



## Эчтәлек

Сүз башы ............ 3

**Хоккей сере**

«Хоккей» сүзе нәрсәне аңлата? ............ 6
Бу уен кайчан һәм кайда барлыкка килгән? ............ 6
Россия хоккееның тарихы ............ 9

**Уен кагыйдәләре**

Мәйданчык ............ 19
Капка һәм капка мәйданчыгы ............ 21
Кәшәкә һәм шайба (алка) ............ 22
Уенчының экипировкасы ............ 23
Уен барышы ............ 26
Команда составы ............ 27
Казыйлар ............ 27
Кагыйдә бозу очраклары һәм штрафлар ............ 29
Ярышлар формуласы ............ 33

**«Ак Барс»**

Клубның тарихы ............ 36
Зиннәтулла Билалетдинов ............ 37
«Ак Барс» командасының 2009–2010 еллар сезонындагы составы ............ 46
«Ак Барс» хоккей клубы йолдызлары ............ 50
«Ак Барс» командасының казанышлары ............ 54

**«Ак Бүре»**

Клубның тарихы ............ 56
Балалар тренеры ............ 58
Көндәлек тренировкалар ............ 61
«Ак Бүре» командасының 2009–2010 еллар сезонындагы составы ............ 63
Чын хоккейчы нинди булырга тиеш? ............ 68

# Содержание

Предисловие ........ 3

**Загадка хоккея**

Что означает слово «хоккей»? ........ 6
Когда и где появилась эта игра? ........ 6
История российского хоккея ........ 9

**Правила игры**

Площадка ........ 19
Ворота и площадь ворот ........ 21
Клюшка и шайба ........ 22
Экипировка игрока ........ 23
Ход игры ........ 26
Состав команды ........ 27
Судьи ........ 27
Нарушения правил и штрафы ........ 29
Формула соревнований ........ 33

**«Ак Барс»**

История клуба ........ 36
Зинэтула Билялетдинов ........ 37
Текущий состав команды «Ак Барс» в сезоне 2009–2010 годов ........ 46
Звёзды хоккейного клуба «Ак Барс» ........ 50
Достижения команды «Ак Барс» ........ 54

**«Ак Буре»**

История клуба ........ 56
Детский тренер ........ 58
Ежедневные тренировки ........ 61
Текущий состав команды «Ак Буре» в сезоне 2009–2010 годов ........ 63
Каким должен быть настоящий хоккеист? ........ 68

Китапта түбәндәге сайтлардан алынган мәгълүматлар файдаланылды:

В книге была использована информация из следующих сайтов:

www.ak-bars.ru
www.tatneftarena.com

*Фоторәсемнәрдән файдаланырга рөхсәт биргәннәре өчен, «БСС – 1000» (Татнефть Арена) ААЖга һәм «ПСК «Татнефть – Ак Барс» ҖЧҖга ихлас рәхмәтебезне белдерәбез.*

*Выражаем искреннюю благодарность ОАО «ЛДС – 1000» (Татнефть Арена) и ООО «СКП «Татнефть – Ак Барс» за предоставленный фотоматериал.*

Учебно-справочное издание

Для детей среднего и старшего школьного возраста

Автор-составитель
**Сибгатова** Гульнара Фаритовна

Серия «Спорт»

**КАК СТАТЬ ЧЕМПИОНОМ?**
ХОККЕЙ

Казань. Татарское книжное издательство. 2010
На татарском и русском языках

Уку-укыту белешмә басмасы

Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен

Автор-төзүчесе
**Сибгатова** Гөлнара Фәрит кызы

«Спорт» сериясе

**ЧЕМПИОН БУЛУ СЕРЛӘРЕ**
ХОККЕЙ

Мөхәррирләре *Э.Т.Кәлимуллина, Г.Ф.Сибгатова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 30.11.2010. Форматы 70×90 $^{1}/_{16}$.
Шартлы басма табагы 5,27. Тиражы 1500 д. Заказ О-1699.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.